БЕРДӘНБЕР ҺӘМ КАБАТЛАНМАС

Чүпрәле районының Кече Чынлы авылының бүгенгесе

> 5

АГУЛЫ ШЕШӘ

«ВТ» хәбәрчесе хәмер сату урыннарын йөреп кайтты

> 7

АЙГӨЛ ӘХМӘТГАЛИЕВА:

«Эти белән әни гомере буе байлык урынына китап җыйды»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 81 (29048) | Җомга | 9 июнь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4 604609 000131

ЧИРГӘ – ЧИК

ДИСПАНСЕРИЗАЦИЯ АВЫРУЛАРНЫ ВАКЫТЫНДА АЧЫКЛАРГА ЯРДӘМ ИТӘ

Һәр унбиш кешенең берсе авыруын белми. Быелгы диспансеризация барышында белгечләр шундый нәтиҗәгә килгән. Төгәлрәк әйтсәк, ел башыннан бирле Татарстанда диспансеризация барышында барлыгы 26 мең чир ачыкланган. Әлеге профилактик чараның ни дәрәҗәдә нәтиҗәле һәм файдалы икәнлеге турында белгечләр гел сөйләп, искәртеп тора. Әмма, шуңа да карамастан, күпләр шушы мөмкинлектән файдаланмыйча, аңа бармак аша каравын дәвам итә, дип күрсәнә алар. Бу нәрсәсе белән куркыныч?

> 6

НУРЛЫ ҺӘМ КҮРКӘМ БӘЙРӘМ



Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм МИҢНЕХАНОВның Сабан туенда катнашучыларны һәм аның кунакларын СӘЛАМЛӘВЕ

Хөрмәтле татарстанлылар! Кадерле дуслар!

Сезне халкыбызның нурлы һәм күркәм бәйрәме – Сабан туе уңаеннан чын йөрәктән тәбрик итәм.

Табигатьнең кышкы йокыдан уянуы, игенченең тырыш хезмәтенә мәдхия, татар халкының юмартлыгы һәм кунакчыллыгы гәүдәләнеше булган, буыннан буынга кадерләп тапшырыла килгән бу бәйрәмдә үзенчәлекле йолаларыбыз, гореф-гадәтләребез, рухи мирасыбыз байлыгы ачык чагылыш таба.

Сабан туе хаклы төстә барлык татарлар, гомумән республикада яшәүче халыклар өчен иң яраткан, көтеп алына торган тантаналы зур вакыйга буларак таныла. Аның мәйданында һәрвакыттагыча төрле милләт һәм дин вәкилләре очраша, татулык, бердәмлек, дустанә мөнәсәбәт хакимлек итә. Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елында ул Татарстанда этномәдәни күптөрлелекне саклау һәм үстерүгә тагын да бәрәкәтле этәргеч бирә.

Бу тантаналарда, әлбәттә, авыл хуҗалыгы тармагында эшләүчеләрне тәбрикләү, алдынгыларны олылап котлау беренче урынга чыга. Аларның фидакарь хезмәте нәтиҗәсендә чәчү эшләре тиешле вакытында тәмамланды, җыеп алыначак уңышның муллыгына һәм республикабызның азык-төлек белән җитәрлек тәэмин ителүенә нныклы нигез салынды.

Сабан туе һәркемгә яшәү дәрте, көч өсти, якты киләчәккә ышаныч һәм матур өметләр уята. Тарих борылыш кичергән чорларда Ватанга мәхәббәт, гаилә иминлеген ныгыту, өлкәннәргә ихтирам, туган телне ярату кебек рухи хәзинәләребезне сакларга һәм үстерергә кирәклеген тою хисе аеруча көчәя.

Бәйрәм һәрберегезгә күңел күтәренкелеге, яхшы кәеф бүләк итсен! Үзегезгә һәм якыннарыгызга сәламәтлек, бәхет һәм иминлек телим!

Сөенечле хәбәр!

2023 елның 5–15 июнь көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 җомга саны	Ташламалы бәя гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~	444 сум 54 тиен
П2409 атнага дүрт тапкыр чыга	Ташламалы бәя гадәти бәясе – ~~1227 сум 30 тиен~~	1051 сум 80 тиен

Реклама 16+

Районнарда ни хәлләр?

Чаллы

Автокалада җәйге каникулда 2400 мәктәп укучысын эшкә урнаштырырга җыеналар. Алар мәгариф, өстәмә белем бирү һәм яшьләр сәясәте учреждениеләре, «Шәһәр яшелләндерү хуҗалыгы» предприятиесендә эшләячәк. Балаларга хезмәт хакы түләү өчен Чаллы бюджетыннан 13,7 млн сум, республика бюджетыннан 5 млн сум акча бүленеп бирелде. Алар көненә 2 сәгать кенә эшләячәк. Бер айга 4060 сум хезмәт хакы вәгъдә итәләр. Шуңа 2250 сум күләмендә матди ярдәм дә өстәләчәк. Гомуми хезмәт хакы 6310 сумны тәшкил итәчәк. Теләге булган 400 яшүсмерне «Кориб», «Чаллы икмәге», «Сатурн», «КАМАЗ», «Чаллы су каналы» кебек зур компанияләргә дә урнаштырырга җыеналар.
(«Шәһри Чаллы»)

Мамадыш

Мамадышта яшәүче Бөек Ватан сугышы ветераны Сәмигулла Миңнеханов 100 яшен тутырды. Юбилее уңаеннан аны район башлыгы Анатолий Иванов котлады һәм бүләк тапшырды. Сәмигулла Миңнеханов Югары Кыерлы авылында дөньяга килгән. Фронтка аны 1942 елның 16 мартында алалар. Башта ул Суслонгер лагеренда була, аннары Смоленск өлкәсенә җибәрәләр. Украинаны, Польшаны фашистлардан азат итүдә катнаша. Сугыштан соң тагын ике ел Белоруссиядә хезмәт итә. Хәзер ул кызы белән яши. Җәен авылда көн күрәләр, ә кышын Чаллыга күченәләр.
(«Нократ»)

Апас

Буа районында узган IV төбәкара «Уйнагыз, гармуннар!» фестивалендә Апастан Ринат Шакиров гран-при иясе булып танылды. Якын дусты чакыруы буенча, тальян гармунын кыстыра да күрше районга юл ала ул. Бирегә Буа районының барлык авылларыннан, Чувашия авылларыннан, Ульяннан бик күп гармунчылар катнаша. «Шулар арасында мин Апастан үзем генә идем. «Бездә бик зур бәйрәм була», – дип дустым чакырды. Чыннан да, Әлки, Әнкабә, Исәк авыллары арасындагы мәйданда чын Сабан туе булды. Ахырдан икенче булып тальяныма татар халык көйләренә тезмә уйнадым да утырып торам. «Котлыйбыз, сез – гран-при иясе», – дигәч, аптырап киттем», – дип шатлыгы белән уртаклашты ул.
(«Апас-информ»)

Аксубай

Район үзәгендә «Безнең ишегалды» республика программасы кысасында эшләр тулы көченә бара. Аксубай ишегалларына 19 миллион сумнан артык акча тотылачак. Быел 14 йорт төзекләндереләчәк. Төп эшләр Чистай ягыннан Аксубайга кергәндә, Золин урамында алып барыла, анда берьюлы 12 ишегалды территориясен төзекләндерәләр. Бирегә подъездларга таба юллар салыныды, каты көнкүреш калдыкларын җыю мәйданчыклары төзекләнделәр, балалар уен мәйданчыклары өлешчә монтажланды һәм спорт мәйданчыгы өчен урын әзерләнде.
(«Аксубай»)

БУЛЫШЫРГА ӘЗЕРБЕЗ

КАЗАНДА МӘГАРИФ МИНИСТРЛАРЫНЫҢ ХАЛЫКАРА ФОРУМЫ БАРА

Белемнән башка ерак китә алмаячакбыз! Казанда беренче тапкыр узган «Киләчәкне күзаллап» мәгариф министрларының халыкара форумында катнашучы һәркем әйтте бу сүзне. Утыз илдән килгән мәгариф түрәләре бездән нәрсәгә өйрәнергә җыена?

tatarstan.ru

Тәүге мәртәбә оештырылган җыенда катнашучылар арасында Мисыр, Сенегал, Мали, Зимбабве, Сүрия Гарәп Республикасы, Берләшкән Гарәп Әмирлеге, Пакьстан, Мьянма, Шри-Ланка, Куба, Венесуэла, Белоруссия, Кыргызстан һәм башка ил вәкилләре бар. Анда барлыгы 40ка якын илдән вәкилләр катнашты. Форумда белем сыйфаты, яшьләр белән эшләү, икътисадны үстерүдә мәгарифнең роле, чит илләрдә рус телен үстерү һәм башка мәсьәләләр турында да сүз барды.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, безнең илләрнең киләчәге – мәгарифне, тәрбияне системалы рәвештә камилләштерү. Тарихи һәм рухи мирасны, традицион кыйммәтләрне саклау, татулык ил мәгарифенең аерылгысыз өлеше булып тора. Рәис форумның мәгариф өлкәсе алдында торган бурычларны хәл итәргә булышачагына ышана.

Рөстәм Миңнеханов республикада чит илләр белән мәгариф өлкәсендә 700дән артык килешү төзелүен, яшь белгечләргә стажировка үтү өчен «Алгарыш» гранты булдырылуын, Татарстан вузларында 21 мең чит ил студенты белем алуын әйтте. Чит ил студентларының күпчелеге – Урта һәм Көньяк-Көнчыгыш Азия илләреннән, шулай ук Якын Көнчыгыш илләреннән. Татарстан бигрәк тә Үзәк Азия илләре белән хезмәттәшлек итә.

Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев чыгышында укытучының мәгариф системасындагы роленә тукталды.

– Нинди генә еллар һәм нәрсә аша гына узсак та, укытучыга хөрмәт, мәгариф системасына мөнәсәбәт югары дәрәҗәдә булырга тиеш, – дип ассызыклады ул.

Россия Президенты Владимир Путин видеосәламендә илнең мәгариф өлкәсендә хезмәттәшлек итәргә ачык булуын һәм мондый аралашуның уңышлы алып барылуын әйтте. Президент сүзләренә караганда, Россия башка илләрдә мәгариф үсеше өчен күп нәрсә эшли.

– Илебезнең мәгариф куәте зур. Ул педагогик һәм фәнни мәктәпләре белән көчле. Соңгы 20 ел эчендә илебезнең бөтен белем системасы яңартылды. Россия иң алдынгы педагогика ысуллары белән уртаклашырга әзер. Бәйсез илләрнең мәгариф өлкәсенә чит калыпларны кертергә тырышу бар, моңа юл куярга ярамый, – диде ул.

Россия Президенты ярдәмчесе Андрей Фурсенко, аның сүзен дәвам итеп: «Бәйсезлекне саклау бөтен дөнья өчен мөһим. Без төрле булуыбыз белән көчле», – диде.

– Заман үзгәреп тора. Барыбыз да – яшьләр дә, безнең буын да гел укып, эзләнеп торырга тиеш. Мәгарифнең чиге юк. Нормаль кеше гомер буе укый һәм үзе дә дөньяны үзгәртергә ярдәм итә, – ди Андрей Фурсенко. – Иң зур проблема – квалификацияле белгечләргә кытлык булу. Кайбер илләр белгечләрне суырткыч кебек үзенә суырып тора. Шуңа күрә җәлеп итә торган эш урыннары булырга тиеш. Без җыелган IT парк – шундый урын.

Россия мәгърифәт министры Сергей Кравцов илдә тормышка ашырыла торган проектлар белән таныштырып, башка ил вәкилләренә дә ярдәм кулы сузарга әзер булуын әйтте. Чит илләр белән берлектә төзелгән мәктәпләр турында да сөйләде.

– Сезнең командаларны да фән олимпиадаларына әзерләргә булыша алабыз. Укучыларны һөнәргә әзерләү турында да әйтер сүзебез бар. Урта һөнәри белем бирү системабыз да камилләшә. Элек вузларга керү модада булса, бүген мәктәпне тәмамлаучы укучыларның 60 проценты көллиятләргә укырга керә. Уртаклашыр өчен тәҗрибәләр җитәрлек, – диде Сергей Кравцов.

Сәрия МИФТАХОВА

САНЛАШУ КАЗАННАН БАШЛАНА

Күрсәтергә һәм сатарга. Быелгы Kazan Digital Week халыкара форумы әнә шул рухта узар, мөгаен. Россия базарындагы IT продукцияне тәкъдим итәргә һәм кызыктырырга максат. IT тармак белгечләрен, фән, сәясәт, бизнесны берләштергән әлеге чара быел федераль дәрәҗәгә чыгып, яңа статуста уза.

Гадәттәгечә, сентябрь ае IT тармакка катнашы булган кешеләрне Казанга җыячак. Башкалада 20–22 сентябрьдә Kazan Digital Week форумы узачак. Казан берничә көнгә мәгълүмати-цифрлы технологияләр, фәнни үзгәрешләр, алгарышлар турында фикер алышу мәйданчыгына әверелачәк. Федераль дәрәҗәдә узгач, кызыксынучылары да Россия белән генә чикләнми, билгеле. Хәзердән үк Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасы, БДБ илләренең активлыгын күрәләр.

Татарстанның дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры Айрат Хәйруллин искә төшергәнчә, коронавирусы елда форум тулысынча онлайн форматта үткән иде. 2022 елда исә форум ишекләре 14 меңләп кеше өчен ачылды, 3 мең кеше аны онлайн рәвештә күзәтте.

– Безнең фикерләр, безнең уйлар, эш ысуллары Татарстан һәм Россия күләмендә генә түгел, дөньяның төрле почмакларында булган катнашучылар өчен дә кызыклы һәм кирәкле дигән сүз бу, – дип саный министр.

Kazan Digital Week форумында, күргәзмә зонасыннан тыш, DigitalSkills чемпионаты, «Киләчәк Уеннары» турниры, тематик фикер алышулар, конференцияләр узачак.

Сүз уңаеннан, Kazan Digital Week форумында яшьләр дә үз проектларын тәкъдим итә ала. Министр Айрат Хәйруллин сүзләренә караганда, студентларның IT проектлары саны буенча Татарстан Мәскәү белән беррәттән бара. Иң яхшыларын форум кысасында тәкъдим итәргә һәм аларга инвесторлар табарга булышачаклар.

– Татарстанда бер ел эчендә IT проектларга грант алган 129 студент-миллионер барлыкка килде, – диде министр. – Моннан 5–10 ел элек IT тармакны яхшы белгән студентка үз бизнесын гамәлгә ашыру өчен миллионнар алырга мөмкинлекне күз алдына китерү дә авыр иде.

Республиканың Цифрлы үсешкә ярдәм итү ассоциациясе советы рәисе Рифкать Миңнеханов исә андый «бай» студентлар саны тагын да ишәячәк дигән өметтә. Аның сүзләренчә, быел тагын 300 студент миллион сумлык грантка ия булырга тиеш.

Форум – саннарда

Бюджеты: 35 млн сум.
Катнашучылар саны: 17 мең. 13,5 меңе – чарага килеп, 4 меңе онлайн кушылыр дип көтелә. Бу – «Россия – Ислам дөньясы. KazanForum» чарасындагы катнашучылардан 1,3 меңгә күбрәк. Хәзергә 681 кеше теркәлү узган.
Катнашучыларга күргәзмәләрен урнаштыру өчен 4 мең квадрат метрга якын урын бүлеп бирелгән.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

САН АРТЫНДА НИЛӘР БАР?

Дөресен генә әйткәндә, парламент утырышларында төрле ведомство һәм министрлык вәкилләренең матур-матур саннар әйтеп хисап бирүен тыңлау кайчак ялыктыра. Әмма эшең шул булгач, нишлисең, тыңламый кая барасың?! Өметле сүзләр язып халыкның күңелен дә күтәрергә кирәк, чөнки заманадан зарланучылар саны арта кебек. Ә бит, бер уйлаганда, ил төрле чикләүләр боҗрасында калган бу заманда, әллә ни тетрәнүләр сизмибез, аяк астында җир селкенми. Бисмилланы әйтеп, «хәзергә» дип куйыйк инде.

Дәүсоветның 44 нче утырышында Татарстан финанс министры Радик Гайзатуллин да 2022 елга бюджет үтәлеше турында чыгыш ясаганда борчылырга урын калдырмады. Европаның, Американың көчле басымы да безне җиргә сузып сала алмавы бераз гаҗәпләндерә дә. Егылу гына түгел, иелмибез дә әле, алай гына да түгел, үсешкә юл тотабыз. Ә министр китергән саннар – шуңа дәлил. Бюджет акчасын һәр тармакка, һәр өлкәгә җиткергәнбез. Җитмәс иде, төрле салымнардан казнага яхшы гына акча кергән. Үз керемнәребез күләме буенча, без ил төбәкләре арасында дүртенче урында икән.

Әлбәттә, без акчабызның шактыен Мәскәүгә җибәреп барабыз. Парламент Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин әйтмешли, соңгы елларда ул табышыбызның 75 процентка якынын тәшкил иткән булган, әмма узган ел 71 процент тирәсендә калган. Тора-бара бу сан кимүгә барса, шәп булыр иде ул. Әле кайчан гына бу сан 50гә 50 иде бит. Хыяллану зыян итмәс, дип күңелне юатыйк та, тагын саннарга күчик әле.

Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды җитәкчесе Алсу Мифтахова куанычлы саннар китереп чыгыш ясаган иде. Тик чыгышының саннарга артык мул булуы парламент Рәисенә ошамады. Җитмәсә, фонд бюджеты үтәлешендә кайбер хилафлыклар турында да сүз чыкты. Мәсәлән, биш миллион сум акчаның кая китүе турында документлар җитенкерәми икән. Алай гына да түгел, Алсу Мифтахова узган ел 567 табибның эштән китүен әйткәч, аның чыгышына мөнәсәбәт бөтенләй начар якка үзгәрде. Бер уйлаганда, кадрлар мәсьәләсе фонд эшчәнлегенә турыдан-туры кагылмый да кебек. Җитәкче медицина хезмәте күрсәтүгә фондтан тиешле күләмдә акча бирелеп баруын, шул ук вакытта закон бозу очраклары да күзәтелүен яшерми-нитми сөйләп бирде. Әмма, Фәрит Хәйрулла улы фикеренчә, фонд Сәламәтлек саклау министрлыгы белән бер тәртәгә җигелеп, кеше сәламәтлегенә бәйле бөтен мәсьәләләрне хәл итәргә тырышырга тиеш.

Җитмәсә, депутат Азат Хамаев та утка кызу өстәде. Телевизордан әти-әниләр үз балаларына дәвалану, катлаулы операцияләр ясау өчен көн саен миллионлаган сум акча сорыйлар. Бу мәсьәлә медицина әһелләрен кызыксындырмыймы, янәсе. Алсу Мифтахова әлеге мәсьәләнең фонд эшчәнлегенә турыдан-туры кагылмавын, дәвалану-операцияләрнең чит ил клиникаларына бәйле булуын әйтеп ялгыш эшләде бугай.

Фәрит Мөхәммәтшин үзебездә табибләр җитмәүне, хастаханәдәге озын-озак чиратларны янә искә төшереп, матур саннар артында яткан проблемаларны күтәрергә, җитешсезлекләрнең сәбәпләрен ачыкларга кирәклеген әйтте дә: «Саннар китергәнче нәрсә эшләп җиткерә алмавыгыз турында да сөйләгез», – дип куйды.

Депутат Камил Нугаев киеренкелекне бераз йомшартырга теләде, фонд без кабул иткән законнар кысасында эшли, җитәкчене генә гаепләү дөрес түгел. Фонд эшчәнлеген тагын да яхшырту, нәтиҗәле итү турында нигә без дә уйланмыйбыз соң, диде. «Мәсәлән, Иминият фонды бюджетын арттыру кирәклеге турында нигә дәшмибез. Кайсыгыз «за» дип кул күтәрергә әзер?» – диде Камил Нугаев. Депутатларның кайбер мәсьәләләргә карата битарафлыгын Фәрит Мөхәммәтшин моңа хәтле дә әйткәләп килә иде. Кеше сәламәтлегенә бәйле фонд эшчәнлеге турында сүз чыккач, күңелен бушатып бетерәсе килде бугай аның. Бит әле фондның контроль функциясе дә бар, ул күпме акчаның кая киткәнен санап, хисап биреп барырга, фонд бюджетындагы фәлән хәтле акча экономия ясадык, дип мактанырга гына тиеш түгел. Акчаны тиешле максатта файдалану – кеше сәламәтлегенә мөнәсәбәтебез дигән сүз. Парламент Рәисенең тел төбендә әнә шундый уйлар иде.

Яшьләр эшләре буенча министр Ринат Садыйковның чыгышы утырышта бик күп вакыт алды. Нотык өчен аңа нибары 20 минут бирелгән иде. Тик сүз шактый озакка сузылды. Моның бер сәбәбе яшьләрнең бүгенге җәмгыятьтәге роле турында зурдан кубып сөйләшүләрнең бик сирәк булуында түгел микән дип уйлыйбыз. Совет чорында яшь буынны тәрбияләүнең сыналган системасы бар иде. СССР җимерелгәч, ул система да юкка чыкты, ә яңасын тәкъдим итә алмадык. Дөрес, 1993 елда Татарстан Югары Советы яшьләр сәясәте турында Республика законы кабул иткән иде. Ул закон яшь буын турында кайгырта башлау өчен бер этәргеч булды. Әмма октябрят, пионер, комсомол тәрбиясе кебек эзлеклелек барлыкка килә алмады.

Министр яшьләр алдында торган проблемалар, аларны чишү юллары турында шактый гыйбрәтле мисаллар, дәлилләр китереп сөйләде. Бу язмада исә бер мәсьәлә тирәсендә генә бераз сүз куертып аласы килә. Бүгенге яшьләргә аерым бер идеология кирәкме? Әлеге сорауга кистереп кенә җавап бирергә ашыкмаскадыр, мөгаен. Беренчедән, әле җәмгыятебезнең үз кыйбласы төгәл генә ачыкланып җитмәгән. Кайберәүләр яшьләрне аерым бер идеология кысасында куып кертмәү ягында. Бу хакта утырышта ачыктан-ачык кычкырып әйтүче булмады үзе, әмма «демократия», «сүз иреге», «фикер төрлелеге» дигән сүзләр ишетелгәләде. Әмма шул ук вакытта яшьләрне фашистик идеология, милли экстремизм чире йоктырудан да сакларга кирәк.

Кыйбласы кеше теләсә нинди агымга ияреп китәргә мөмкин. Депутатның ни әйтергә теләве аңлашыла, әнә Украинада тулыр-тулмас утыз ел эчендә нинди буын тәрбияләнде. Аерым бер милләтне Җир шарының теләсә кайсы почмагында юк итәргә чакыруны ничек аңларга һәм аңларга? Депутат Хафиз Миргалимов исә: «Идеология булмаса, батырлык күрсәтеп буламы?» – дип сүз башлады да, бөтен нәрсә акчага корылган бу заманның яшьләргә нинди тәрбия бирәсен фаразлап алды. «Патриотизм» дигәннәре акчага сатыла башласа, нишләрсең? Әлбәттә, бу хис инде ватанпәрвәрлек булмас.

Фәрит Мөхәммәтшин яшьләрне тәрбияләүнең теләсә кайсы җәмгыять өчен фундаменталь мәсьәлә икәнен искә төшерде. Хикмәт нинди кеше тәрбияләүдә бит!

Утырышта Татарстанда Конституция Советы оештыру турында закон проекты каралган иде. Ул илдә хакимият вертикален ныгытуның тагын бер чагылышы инде. Татарстанда Конституция Суды бетерелгәч, аның вәкаләтләрен Конституция Советына бирмәкчеләр. Кабул ителгән законнарның, карарларның төп закон таләпләренә туры килү-килмәвен шул совет тикшерәчәк һәм юридик яктан бәяләп, дәүләт органнарына юллаячак.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

gossov.tatarstan.ru

Кичәге утырышта күршеләребез – «Республика Татарстан» газетасына яңа баш мөхәррир дә билгеләнде. Газетаны егерме елга якын җитәкләгән Александр Латышевка алмашка Александр Угаров килде. Депутатлар аның кандидатурасын бертавыштан хуплады. Александр Латышев массакүләм мәгълүмат чараларында күп еллар буе нәтиҗәле эшләве өчен Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләнде.

ТАБИГАТЬ САГЫНДА

Чүп җыясың, агач утыртасың, тирә-якны матурлыйсың һәм үзеңә башкаларны иярттәсең. Әле җитмәсә, бүләк тә эләгә. Татарстанда санитар икеайлык кысасында оештырылган «ЭкоЯз» бәйгесендә җиңгән гаилә Санкт-Петербургка юл тотачак.

Чистайда яшәүче Степановлар бу бүләккә әле дә ышанып бетә алмыйлар. Иртәдән торып, барысы да матур итеп киенеп, Казанга юл тотканнар. Ике кызлары Маша белән Настя – мәктәп укучылары, кечкенә уллары Александр әле бакчага йөри. Әнә шул бакчада тәрбияче булып эшләүче әниләре Ольга бу бәйге турында ишетеп кайта да инде.

– Без моңа кадәр дә табигатькә битараф түгел идек. Чүпләмәскә тырышабыз. Тирә-якны чиста тотабыз. Үз йортыбыз белән яшәгәч, эш тә күп. Тәртиплисе урыннар да җитәрлек. Уйлаштык та, гаиләбез белән бәйге өчен мультфильм төшерергә булдык. Махсус программа белән эшләдек. Энтәлеге болайрак: кече кызыбыз суга пластик шешә ташлый. Олысы исә алай эшләргә ярамавын кисәтә. Суга кергәч, чүпнең тагын да күбрәк булуын күрәләр дә бергәләп сулыкны чистарта башлыйлар. Башта рәсемен ясадык, аннан шул курчакларны сөйләштерә башладык. Менә монысы җиңел бирелмәде. Мультфильмны ясар өчен 1 атна вакыт кирәк булды, – ди Ольга.

Шул мультфильмга бар эшләрен кертә алар. Тирә-якларын да күрсәтәләр. Бакчаларына матур итеп яшел почмак ясап куялар. Әтиләре машина тәгәрмәчләрен эшкә җигә. Үзенекеләр генә җитмәгәч, күршеләрдән сорыйлар. Шуларны акка буяп, матур итеп өеп, җәннәт бакчасы ясыйлар.

Степановлар, киләчәктә дә төрле бәйгеләрдә катнашачакбыз, диләр.

– Республикада елдан-ел экологиягә зур игътибар бирелә. Халык та битараф түгел. Шәхси йорт белән яшәгәч, үзең дә сизмәстән тирә-якның чисталыгын кайгырта башлыйсың. Ә инде менә мондый бәйгеләр тагын канат куя. Җиңүче дип котласалар да, әле дә ышанып бетә алмыйбыз. 5 кешелек гаиләбезгә Санкт-Петербургка юллама алу турында уйлап та карамаган идек, – ди Сергей Степанов.

«ЭкоЯз» бәйгесендә катнашу өчен быел 143 гариза килгән. Икеайлык кысасында 750 мең кеше чистарту өмәләрендә катнашкан.

– Бүген эшләгән эшләр киләчәк өчен башкарыла, – ди Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министры Александр Шадриков. – Әлеге бәйге 8 ел рәттән уздырыла. Катнашырга теләк белдерүчеләр арасында мәктәп коллективлары, балалар бакчалары, гаиләләр күп. Бергә булганда гына без сулыкларны, урман-кырларны, сулар һаваны чистарта алабыз. Кайда гына булсак та, ни генә эшләсәк тә, максатыбыз бер безнең.

Сүз уңаеннан, «Иң яхшы басма матбугат» номинациясендә хезмәттәшебез Гөлгенә ШИҺАПОВА җиңү яулады.

Әйтеп кенә бактым

Барыбыз да бертигез

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Торам-торам да хатынның колагын борам, дигәндәй, шифаханәдә ял иткән чак искә килә дә төшә, килә дә төшә. Юкса әллә нинди маҗаралы хәлләргә дә тарымадым, күңелсезлекләр дә килеп чыкмады. Телефоннан шалтыратып сораганнарга: «Мин ближнее зарубежьеда әле», – дип җавап бирә тордым. Артык борчымасыннар әле, янәсе.

Мин ял иткән «Кленовая Гора» шифаханәсе Казаннан нибары 90 чакрым тирәсе, машинада сәгать ярымлык юл. Әмма, ни гаҗәп, бу яклар миңа шактый үзгә тоелды. Мари урманнары уртасында әйтерсең лә СССР дигән илнең бер өлеше адашып калган. Биналар, җиһазлар шактый искергән, таушалган. Номерлар кысан, стенада амбар кенәгәсе хәтле генә телевизор. Шифаханә бинасы инде күптән ремонт күрмәгән һәм күрмәс тә. Ул профсоюзныкы исәпләнә икән, ә профсоюз үзе бармы-юкмы – бу турыда уйлаган кеше дә юк. Ашханәдәге ризыклар да бик үк «изысканный» түгел, әмма бәрәңгесен, итен, токмачын җәлләмиләр. Әле җитмәсә, өстәлләргә ризык таратучы Вера һәрвакыт: «Барыгызга да җиттеме? Добавка кирәк булса, әйтегез. Ашларыгыз тәмле булсын!» – дип күңелне күтәреп куя. Мин аңа үз телендә, ягъни марича рәхмәт әйтәм: «Верочка, кугу тау (зур рәхмәт)!» – дим. Әй, күңеле була Вераның! Кешене шатландыру өчен күп кирәкмени! Ашап утырганда да безнең өстәл янына килеп киткәли башлады Вера, янәсе, бездә бар та тәртиптәме? Мин: «Чыла сай (бөтенесе дә әйбәт)», – дип, аны тагын рәхмәтләргә күмәм.

Шифаханәдә артык купшы номерлар да юк, процедуралар да, ашау-эчү дә бар кешегә бертөрле. Бары тик диабетиклар, ашказанының рәте киткәннәр өчен аерым өстәлләр куелган.

Шунысына игътибар иттем: монда ял итәргә килүчеләр арасында үзләрен җәмгыять каймагы санаганнар гүпчи күренми. Барысы да, фәкыйрь-фокра ук булмасалар да, урта хәлләләр диярлек була. Шуңа күрә бер-берсе белән сүзләре дә килешә. Шифаханә бинасыннан чыгып, ишек төбендәге эскәмиягә барып утырдыңмы, синең янга теләсә кем килеп исәнләшеп, күптәнге танышы кебек сүз башлар һәм сөйләшер сүзләр дә табылыр.

Әйе, СССР вакытындагы кебек, барыбыз да бертигез. Хәтта бердәнбер эт белән алты мәче дә бертигез хокукта. Ашый торган урыннары – бина каршындагы чирәмлек һәм уртак савыт-саба. Савыт-саба дигәнем өч җамаяк инде. Зуррагы – этнеке. Тик эт алдына салганның барысын да ашап бетерми, беразын мәчеләргә калдырып, читкәрәк китеп ята. Эт – командир сымак. Ашау вакытын сәгате-минуты белән белеп, ишек төбенә килеп баса да, чыккан берсенең күзенә карап, койрык болгап тора. Янәсе, безгә бу юлы нәрсә алып чыктың? Буш итмиләр, ач калдырмыйлар аларны. Мондагы халык та, эт белән мәчеләр дә «бары – бергә, югы – уртак» дигән принцип белән яши.

Язганнарым, бәлки, шыттыру кебек тә тоелыр. Әмма укучым алдында деге бөртеге кадәр дә гаебем юк, ни күрсәм – шуны яздым. Инде менә мондый тигезлек җәмгыятьтә була аламы соң, дип уйланып утырам. Бөтен кеше бертигез булсын өчен һәммәсе дә йә фәкыйрь, йә урта хәлле, йә бай булырга тиешме? Мәҗит Гафури язганча, җәмгыять ярлы, зарлы, моңлы кешеләрдән генә тора алмый бит инде. Тигезлек табигатьтә дә, гомумән, бөтен дөньясында була алмый. Булса, дөньядагы төрле дәүләтләр дә ызгышып-талашып яшәмәс иде. Тик менә ни өчен миңа Мари урманнарында СССРның бер өлеше адашып калган кебек тоелды икән? Мөгаен, кешеләрнең үзара әчкерсез мөгамәләсе, бер-беренә ярдәм итәргә торуы шундый уйларга этәргәндер. Монда ял итүчеләр яңа килгәннәрне каршы ала, китүчеләрне озатып та кала әле. Үзләре теләп бит бу!

Олыгайган саен, кеше консерваторга әйләнә бара, диләр. Ә шифаханәләргә, гадәттә, өлкәннәр генә килә. Мин ял иткәндә яшьләр бөтенләй юк иде. Димәк, алар белән бергә СССР вакытында ук урнашкан әхлак нормалары, матур йола-гадәтләр дә киләдәр һәм һәркем шул чорда тагын бер кат яшәп алады.

Англия Премьер-министры Черчилльнең бер кызыклы фикере искә төште әле. «Картайгач, консерваторга әйләнмәгән кешенең башында мие булмый…» – дигәнрәк сүзләр әйткән булган ул. «Кленовая Гора»да ял итмәгән заманының атаклы сәясәтчесе, әмма кешенең үткәненә кайта-кайта яшәвен үзенчә әйткән дә биргән. Адәм акыллары булган икән, диярсең.

ЧЕРЧИЛЛЬ ТОСТЫ,

ЯКИ ҖАЙ КИЛЕП ТОРУ

Бу юлларның авторы, көннәр җылыткач, көн саен диярлек велосипедта ун километр тирәсе юл узып кайта. Күбрәк тигез асфальт юлны сайлый, кайвакыт басу юллары буйлап та китә. Икенчесе әллә никадәр хис уята: табигатьнең онытылып барган почмакларын күрәсең, яшьлекне искә төшерәсең.

Педаль әйләндерергә мине тән сызлавы мәҗбүр итә. Гел утырып эшләгән кеше белә: хәрәкәтсез утыру сиңа бер бәйләм чир бүләк итә. Велосипедта йөрү шул аз хәрәкәтне компенсацияләү өчен кирәк. Тән языла, авыртулар бетә. Дөрес, педаль әйләндергәндә дә чамалы белү таләп ителә. Каударланып кызуланасың икән, сәламәтлек урынына чир ияртеп кайтасың. Артык ерак китсәң дә шулай ук. Авыл урамына кергәч, кайвакыт танышлар янына тукталасың. Соңгы тукталышларның берсендә танылган табиб булган танышым, велосипед яратуымны белгәч: «Туксанга кадәр яшәрсең», – диде. «Юк, – дидем мин, – әҗәлемнең вакыты билгеләнгән инде, мин аны үзгәртә алмыйм. Велосипедта йөрү миңа бүгенгемне сәламәт яшәү өчен генә кирәк».

Велосипед үлемнән качарга булышмый, чөнки Коръәннән Аллаһы Тәгаләнең сүзләрен беләм: «Сез аңардан куркып качкан үлем – сезне каршы алучыдыр…» (62 сүрә, 8 аять тәфсире), ягъни кай тарафка гына качма, үлем сине куып мәшәкатьләми, ә каршы ала. Әҗәл вакыты җиткән икән, чара юк, вакыты җитмәгән булса, пуля яңгыры аша да исән узачаксың, меңнәр егылып үлгәндә, син исән калачаксың. Бу юлларның авторы белән булды андый хәл: ул узып киткән урында, аз гына вакыт үтүгә, ике меңнән артык кеше фаҗигале рәвештә һәлак булды. Аз гына соңга калсам, мин дә шулар исемлегендә булачак идем. Ул көннең фаҗигасен мәгълүмат чаралары сәгатендә үк бар дөньяга хәбәр иттеләр. Мин исә гаиләм белән кичкә кадәр элемтәгә керә алмадым һәм туган илдә корбаннар исемлегендә булуыма ышана башлаганнар инде. Кичен, телефоным эшли башлау белән, кызымның: «Әти, син исәнме?» – дигән борчулы тавышын ишеттем. Гади кеше акылы белән фикерләсәк, берничә минут соңга калу мине үлемгә китерергә тиеш иде. Әмма, гафу итегез, ул вакытта яшәп калуым котылгысыз иде. Шул котылгысызлыкны аңлау күңелгә тынычлык бирә, кирәкмәгән стресстан коткара.

Күңелсез тема күтәрәсең дип, гаепләргә ашыкмагыз. Сүзем үлем түгел, яшәү турында. Тәкъдирнең без белмәгән һәм аңлый да алмаган бер серле ягы хакында сөйләргә телим. Руслар аны «везение» диләр, татарчага бар нечкәлекләре белән тәрҗемә итеп булмый, «җай килү» дип алабыз.

Мин үзем исерткеч эчемлекле мәҗлесләрдә утырмыйм, тостлар әйтмим. Тост – аракыга гыйбадәт кылуның бер үрнәге, мәҗүсилек ул. Үзен динсез дип санаган кешеләр шулай дога кыла, үзләре өчен мәҗбүри дип саналган ритуалны үти. Бу – аларның дине. Бөекбританиянең мәшһүр Премьер-министры Черчилль бервакыт эчемлеккә болай дип дога кыла: «Берәүгә дә сәламәтлек тә, байлык та теләмим. Бары тик тормышта җай килеп торуын гына сорыйм. «Титаник»та бит күпчелек сау-сәламәт һәм бай булган. Бик азларына гына җай килеп, исән калганнар». Исерткеч аның ул догасын үтәргә булышмаса да, Черчилль, чыннан да, мин язма башында әйткән фикерне куәтли: сәламәтлек һәм байлык үлемнән коткармый, тәкъдирнең безнең акылга сыеп бетми торган борылышы гына сулар аша да, утлар аша да исән калып чыгарга булыша. Без «везение» (җай килү) дип атыйбыз атавын, әмма ни өчен шулай булуының серенә төшенә алмыйбыз. Без уңышсызлык дип санаган нәрсәләр көтелмәгән уңышка әйләнә андый чакта, адәм баласы сукранып һәм ярсып кабул итә торган хәлләр шөкер итәргә тиешле коткару тәгәрмәченә әверелә. 2013 елның 17 ноябрендә Казан аэропортындагы очкыч һәлакәтен хәтерлисезме? Җир җимертеп йөргән һәм, безнең күзлектән караганда, әле яшәргә дә яшәргә тиеш булган бик күпләр һәлак булды анда. Танылган бер татар артисты рейска соңга калды… Соңаруын ул башта кәефе кырылып кабул иткәндер, бәлки, уңышсызлык дип санагандыр. Нью-Йорктагы 11 сентябрь фаҗигасендә дә күпләр белән шулай була: кемдер, аягын ботинка кыру сәбәпле, даруханәгә кереп соңга кала, кемнеңдер машинасы кабынмый, кемнеңдер сәгате шалтырамый… Нәтиҗәсе барысының да бер: исән калу. Болар берсе дә очраклылык түгел, әлбәттә.

vk.com

Бу юллар авторы үз тормышында гел игътибар итә: кайбер нәрсәләргә, күпме генә омтылмасын, ирешә алмый. Еллар үткәч кенә аңлыйсың: уңышсызлык дип кабул иткән ул хәлләр хәерлегә булган икән. Руслар әйтәләр бит әле: «Невеста ушла к другому, неизвестно кому повезло», – дип. Гомернең күп кенә борылышлары белән шулай килеп чыга. Ә менә кайбер нәрсәләр көтелгәнгә караганда да җиңелрәк бирелә. Әйтик, вузда үземне тырышып укыдым дип әйтә алмыйм. Вәләкин кызыл диплом белән тәмамладым. Имтиханнардан бәхет бар иде чөнки, «җай килә» иде. Гамәли дәресләргә әзерлексез йөрү сәбәпле, имтихан белән янаган укытучылар булгалый иде. Андый чакларда һәрвакытта да: «Сез борчылмагыз, сезнең имтиханны «бишле»гә бирәчәкмен», – дип әйтә идем. Кырыслыгы, принципиальлеге белән нык аерылып торган Людмила Ивановна Коноваловага гына андый сүз әйтә алмадым. Берничә гамәли дәрестә «икеле» алганнан соң, ул, вуз коридорында туры китереп, әниләрчә кайгырту белән минем имтиханым өчен бик борчылуын әйтте. Мин эндәшмәдем, чөнки, бердән, ул укыткан «Старославянский язык» – бик катлаулы фән, икенчедән, укытучысы бик таләпчән иде. Имтиханда беренче сорауга җавап бирмәсәң, икенчесен сөйләтеп тә тормыйча «икеле» куя торганнардан иде. «Старославянский язык» имтиханына мин алтмыш сорауның илле тугызына бик яхшылап әзерләндем, бер сорауның җавабын аңлый алмадым. Һәм күз алдыгызга китерегез: имтихан билетында мин җавабын белмәгән шул сорау туры килде. Бу катастрофага тиң. Әмма мин имтиханны «бишле»гә бирдем, бер уңайдан сорауның җавабын да белеп чыктым. Юк, күчермәдем. Ярдәм күктән төшкән кебек ишелеп төште. Шулкадәр көтелмәгән рәвешле килде: хәтта елмаюын аңарчы беркем дә күрмәгән Людмила Ивановна да рәхәтләнеп көлде: «Бу сорауның җавабын башкалар биш кат аңлатсаң да аңламыйлар әле», – диде дә «бишле» куйды.

«Боларны ник язасың?» – дип сорарсыз. Тәкъдир бик серле рәвештә корылган. Әмма аның һәр борылышы безнең өчен файдалы. Тормышта бар нәрсә дә без теләгәнчә һәм җиңел барса, ул үзе катастрофага әйләнер иде. Теләкләребезнең тормышка ашмавы күп чакта Черчилль әйткән «везение» үзе инде. Шуңа күрә язмыштан зарлану – стресстан башка берни дә бирми торган мәгънәсезлек. Риза булып яшисең икән, тулы канлы тормыш кичерәсең. Гомереңнең ахырына тыныч күңел белән атлыйсың. Үлемне гаиләсенә һәм танышларына «риза-бәхил» дип әйтеп каршылый алучылардан күңелдә якты эз кала. Русча әйтсәк, боларга «повезло», чөнки яшәүнең һәм үлемнең асылын аңладылар.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Зөлфия Хәлиуллина

Зөһрә САДЫЙКОВА

БЕРДӘНБЕР

Авыл гөрләп яшәсен өчен халкының эш белән дә, аш белән дә тәэмин итәрлек шартлары булырга тиеш. Чүпрәле районына баргач, әлеге фикеремә тагын бер кат инанып кайттым. Кече Чынлы – районда иң зур, төзек, матур авылларның берсе. Хуҗалык саны, яшәүчеләре буенча иң алдынгысыдыр да әле. Тик авылның колхозы, күмәк хуҗалык чорларыннан таралмаган-таркалмаган «Цильна» җәмгыяте һәм аның легендар җитәкчесе Барис Гафуровның үҗәтлеге булмаса, бүгенгесе мондый ук була алыр идеме икән? Шикләнәм.

«Бердәнбер булу җиңел түгел»

Әлеге вакытта колхозның 3200 сыеры, 5200 гектар җире бар. Бүген алар тәүлегенә 35 тонна сөт җитештерә, районның 7 процент җирен били, 50–60 процент продукциясен бирә. Тик заманында хуҗалыкны мөстәкыйль итеп саклап калыр өчен Барис Гафуровка утны да, суны да кичәргә туры килә.

– Хуҗалыкны инвесторларга бирмәс, мөстәкыйль итеп саклап калыр өчен миңа бик нык тырышырга туры килде, дип әйтү генә аз булыр. Дөресен әйткәндә, мин күргәнне башкаларга күрергә язмасын, – ди ул. – Мин – Югары судлар аша узган кеше. Колхозны анда да яклап кала алдым. Бу төбәкләрдә без – үз-үзенә хуҗа булган бердәнбер хуҗалык. Тик бердәнбер булу да җиңел түгел. Шуңа күрә эшләгәндә комачауламасыннар да җан тынычлыгы булсын иде, дип телим.

Әлеге вакытта хуҗалыкта эшләүчеләрнең төп умыртка баганасы – 45–50 һәм аннан өлкән яшьтәгеләр. Барис Гафуров әйтүенчә, бүгенгә эшчеләр җитсә дә, киләчәк уйландыра.

– Яшьләр бик аз кала. Авыл хуҗалыгы белгечлегенә укыган егет һәм кызлар да кабат авылга кайтмый, – ди җитәкче. – Ярый да миндә әлегә аларга кытлык юк. Бездә җиде мал табибы гына эшли. Ә менә механизатор, терлекчеләр җитми. Мин үземдә эшләгән кешеләрдән бик канәгать. Бездә тырыш, уңган халык. Монда эшләгәннән тыш үз абзарларында күпме мал тота алар. Унышар сыер савучылар, 4–5әр баш үгез тотучылар бар. Кош-кортларын телгә дә алмыйм. Аны әйтергә генә җиңел. Күпме хезмәт сорый бит ул. Әгәр кеше сыерын бер тапкыр бетерә икән, икенче тапкыр алмаячак ул. Ә авылда терлек беттеме – ул авыл бетте дигән сүз. Барысы да безнең күз алдында, фермалары ябылгач, никадәрле авыл бетте районда.

Колхозның ярдәме булмаса, халкы шуның кадәр терлек асрый алыр идеме икән? Ай-һай. Барис Аппаувич моны үзе дә яшерми. Печәнен, ашлыгын, сенажын биреп тора. Ишекка сак та бастырмаган, йозак та элмәгән.

> Үзенә җитәрлек кенә алып кайтканына сүз әйтмим. Бүген сөт бәяләре төште. Әгәр шундый шартларда мин дә аркылы төшсәм, кешеләр малларын зыянга гына тотар иде. Ә миңа эшчеләремнең көндәлек тормышлары, яшәү шартлары яхшы булуы бик нык мөһим. Җитәкче кеше шундый булырга тиеш тә. Эшчем гаиләсен, балаларын карарга, ашатырга-эчертергә, киендерергә, укытырга тиеш», – ди Барис Гафуров.

Бу авыл халкы ул яктан зарлана алмый. Электән үк ул, баласы тугач, Казаннан яки Буадан фатир алып куя иде. Чөнки күпләп мал тота, ат урынына эшли ул. Миңа да ярдәм сорап күп керәләр. Кире борып чыгарырга тырышмыйм. Ел саен хәйрия өчен ким дигәндә 6 млн сум акча бүлеп бирелә. Моның өстенә авылда узган Сабантуй чыгымнарын тулысынча үзебез күтәрәбез, районыкына да төп ярдәмне без күрсәтәбез.

Нинди генә көчле хуҗалык булса да, һәр чорның үз авырлыгы бар. Хәзер дә колхоз җитәкчелегенә яңа сынаулар каршында тора.

– Узган ел белән чагыштырганда, сөт бәясе 13 сумга төште. Шуның аркасында без аена 13 млн сум акча югалтабыз, – ди Барис Гафуров. – Легаль һәм легаль булмаган юллар аша кергән порошок белән бөтен дөнья тулды. Аннан ясалган сөтнең үзкыйммәте 12–13 сумга төшә. Шулай булганда заводлар бездән сөтне ни өчен 30 сумга сатып алсыннар ди? Тикшерү органнары кая карый икән? Бу проблеманы бер район, республика дәрәҗәсендә генә хәл итеп булмый. Ул югарыда хәл ителергә тиеш. Ашлыкның бәясе узган ел белән чагыштырганда 50 процентка төште. Көзен, бәлки, бераз артыр ул, ләкин безгә акча бүген кирәк. Эшчеләрнең хезмәт хакы 30 процентка артты. Ягулыгы, техникасы, Сабан туен уздырырга кирәк. Бөтен авырлык авыл кешесенә төшә. Бу авыр хәлдән без бары тик җитештерүне арттырып кына чыга алабыз. Башка чарабыз юк. Безнең продукция дә бар, җитештеру дә көчле, аякта нык басып торабыз. Әле шулай була торып та, авырлык сизәбез. Башкаларда терлек тә, эш тә калмады әнә. Мин үзем энергияне эштән, күрелгән нәтиҗәләрдән алам. Шуңа күрә тонуста тотар өчен авырлыклар да бар, сөенер өчен уңышларыбыз да җитәрлек.

«Акчасын алгач, ял итәсең»

Авыл җирлеге башлыгы Гомәр Халитов әйтүенчә, авылда 570 хуҗалыкта 1200 кеше яши.

– Бездә фермерлар да, бакчачылык белән шөгыльләнүчеләр дә юк, халык терлек асрап көн итә, чөнки шартлар бар. Сөт бәясе төшү генә күңелне кырды быел. 9 сумга кадәр төшә икән, дигән сүзләр дә йөри. Шулай барса, көзгә малларны киметәбез, дип әйтүчеләр дә бар, – ди ул.

Әлегә район буенча шәхси хуҗалыкларда иң күп терлек тә – Кече Чынлы авылында. 2 меңнән артык баш мөгезле эре терлек, шуларның 450се – савым сыеры. Ныклы хуҗалыгы булгач, халыкның күпчелеге төенчеген төйнәп, бәхет эзләп чит җирләргә чыгып китмәгән. Аны туган туфрагында тапкан.

Әйтик, Гөлүсә һәм Ринат Сабитовлар гаиләсе ун сыер сава, бозаулары, атлары, кош-кортлары бар. Гомер буе авылда яшәп, колхозда эшләп, терлексез яшәүне күз алдына да китермәгән күп гаиләләрнең берсе алар.

– Терлек тотар өчен башта аны яратырга, икенчедән, мөмкинлек булу кирәк, – ди хуҗабикә Гөлүсә апа. – Колхозыбыз зур, көчле, азыкны каян, ничек табыйк икән, дип борчыласы юк. Ашлыгын, печәнен, сенажын, саламын биреп торалар. Сөт һәм ит саткан акчага рәхәтләнеп яшибез. «Сөткә хак төште», – дип тә елап утырып булмый, тамчыдан күл җыела ул. Сыерны бетереп була аны, тик андыйны тагын каян табасың? Яхшы сыер булсын өчен ничә ел тырышабыз бит. Аллага шөкер, сыерларыбыз сөтле. Бүген 180 литр сөт тапшырам. Буаз сыерларыбыз да бар. Терлекне эшкәртеп, итен шәһәр халкына сатабыз, Шыгырданнан да алып китәләр. Бетерү турында уйлап та караганыбыз юк, бер дә зарланып булмый. Кешенең кәсебе булырга тиеш. Нужасыз булмый инде ул. Тик башта арыйсың да, акчасын алгач, ял итәсең.

Кем белән генә сөйләшсәк тә, Барис Гафуровка рәхмәтләрен әйтә. Республиканың шактый авылларында булганга күрә, чагыштырып карау мөмкинлегебез бар. Мондый күренеш эш тәҗрибәмдә бармак белән санарлык булды. Без махсус сорамасак та, сүз очы үзеннән-үзе колхоз җитәкчесенә барып ялганды.

– Колхозыбыз гына яшәсен. Ул болай барганда, безгә зарланырга оят булырга тиеш. Барис абыйга рәхмәт, безнең бәхеткә исәнлеге булсын. Йомышыбыз төшсә дә, аның янына барабыз. Кире борып чыгарганы юк, – диде Гөлүсә апа.

Ринат абый колхозда механизатор булып эшли.

– Айга 50 мең сум хезмәт хакы алам. Аны икегә бүлеп бирәләр. Мин канәгать, – диде ул тыйнак кына.

Хәер, колхозда эшләүчеләрнең берсе дә игътибардан читтә калмый, дигән тәэсир калды бездә. 30 ел гомерен колхозда сыер савуга багышлаган Зөлфия Җаббарова да сыерлары, фермадагы хезмәте турында шулкадәр яратып, тәмләп сөйләде. Аның турында газетаның алдагы саннарында иркенләбрәк язарбыз әле.

– 55 сыер савам, аларның һәркайсын яратам. Көтү арасыннан шундук танып алам. Холыкларына, кәефләренә кадәр аерам. Җәен 40–45 мең сум хезмәт хакы алабыз, кышын тагын да күбрәк була. Өйдә дә маллар тотабыз, шуңа күрә рәхәт тормышта яшибез, – диде ул.

Бездән соң кем?

Авылның 82 укучысы булган мәктәбе, 16 бала йөрүче балалар бакчасы, ике мәчете, берничә кибете, мәдәният йорты, ФАП бар. Быел мәдәният йорты, бер мәчетләре капиталь төзекләндерелгән. Без «Ихлас» мәчетенә кергәндә авыл агайлары намазга җыелган иде. Мәчетнең мәзине Рифкать Җәләлетдиновның да бар гомере шушы авылда узган.

– Мин 1976 елда авыл хуҗалыгы техникумын бетереп кайттым. 1985 елда Барис Аппаувич белән колхозда бергәләп эшли башлаган идек, 2013 елда пенсиягә чыкканчыга кадәр, шушында булдым. Ул килгәч, шәхси хуҗалыкларга печән, иген бирә башладылар, көнкүреш шартлары яхшырды. Өлкәннәр көнегә бүләкләр тараттылар. 1990 елда беренче мәчет салынды. 2003 елда авылның икенче башында икенче мәчет сафка басты. Колхоз ел саен Корбан бәйрәмендә ике тана бирә. Без аларны эшкәртеп, авылдагы һәр кешегә өләшәбез. Борис Аппаувич кына исән булсын. Ул булганда, без яшибез әле. Инвесторлар кергән булса, без күптән бетәсе идек, – диде ул.

Барысыннан да канәгать булып яшәсәләр дә, авылның киләчәге авыл агасын да уйландыра булып чыкты.

– Колхозыбыз көчле булганга күрә, мин авылдан бер генә көнгә дә китмәдем, чөнки эше булды, акчасын түләде, абзар тутырып мал тоттык, – диде Рифкать Җәләлетдинов. – 70 яшь булса да, бүген дә ике сыер савам, аның ике бозавы бар. Авылда яшәү яхшы, тик яшьләрнең калмавы гына күңелсез. Эш бар, терлек күп. Рәхәтләнеп тырышып яшә генә. Без, өлкәннәр, китеп беткәч, авыл кем кулына калыр? Безне хәзер шушы сорау гына борчый.

Динә
ГЫЙЛАҖИЕВА

ЧИРГӘ – ЧИК

pexels.com

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Әби онычын иярттә

Быелның дүрт аенда республикада 400 меңләп кеше диспансеризация узган. Аның барышында республикада яшәүче һәр 15 кешенең берсендә теге яки бу чир барлыгы ачыкланган. Алар бу хакта беренче тапкыр нәкъ менә диспансеризация вакытында белгән. Дүрт ай дәвамында ачыкланган чирләрнең күпчелеген (30 процент) элеккечә үк йөрәк-кан тамыры авырулары тәшкил итә. Ел башыннан бирле 265 кешедә яман шеш тапканнар. Шуларның 75 проценты башлангыч чорда ачыкланган.

Билгеле булганча, 2021 елның 1 июленнән Россиядә җентекле диспансеризация дигән төшенчә гамәлгә керде. Ул коронавирус белән авырып терелгән кешенең сәламәтлеген тулысынча тикшерү, мәкерле чир аркасында өзлегүләрне кисәтү өчен уздырыла. Быел аны республикада яшәүче 118 меңнән артык кеше узган.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш терапевты, Республика клиник хастаханәсенең терапия клиникасы җитәкчесе Диана Габделганиева сүзләренә караганда, диспансеризациянең файдасы турында күпме генә сөйләнсә дә, халыкның күпчелеге, бигрәк тә яшьләр анда барырга атлыгып тормый. Шулай да соңгы арада хастаханәләрдә шундый кызыклы хәл күзәтелә башлаган. Диспансеризацияне вакытында һәм җиренә җиткереп узып барган өлкәннәр үзләре белән яшьләрне дә иярттеп килә башлаган.

– Соңгы арада диспансеризациягә гаиләләре белән килүчеләр күбәйде. Бу бик сөендерә. Юкса моңа кадәр бу эшкә яшьләрне җәлеп итү авыррак иде. Үзләрен яхшы хис иткәч, алар моны артык мәшәкать итеп кенә кабул итә. Чирләр дә каядыр еракта – картлыкта гына көтеп торадыр кебек тоела. Әмма авыру яшькә карамый шул. Диспансеризация, барыннан да бигрәк, юан эчәклек, тән тиресе, күкрәк яман шеше кебек зәхмәтне башлангыч чорда ук ачыкларга ярдәм итүе белән әһәмиятле. Шикәр чире, атеросклероз кебек чирләрне кисәтүдә дә аның өлеше бик зур, – дип сөйләде белгеч «ВТ» хәбәрчесенә.

Берничә көн элек Казанга Мәскәүнең Терапия һәм профилактик медицина илкүләм тикшеренүе үзәге белгечләре килде. Алар Әлки район хастаханәсендә, Казанның 20 нче һәм 7 нче номерлы шәһәр хастаханәләрендә дә булды.

– Бирегә килгән халык белән аралаштык. Кайсы белән генә сөйләшмә, барысы да диспансеризацияне кирәк дип саный. Шушы тикшеренү вакытында берәүнең күршесендә шикәр чире, икенчесенең эчәклегендә полип тапканнар. Һәркайсының әнә шундый мисалы бар, – ди Диана Габделганиева.

Белгеч яшерми: бүген арабызда диспансеризацияне ахыргача үтеп бетермичә, ярты юлда калдыручылар да шактый. Моны зур хата дип саный ул. Ник дигәндә, ахыргы нәтиҗәне табиб-терапевт чыгара. Диспансеризация барышында узган барлык тикшеренү, анализ нәтиҗәләре буенча алга таба ни эшләргә кирәген дә нәкъ менә ул ачыклый.

Сизгәндә соң була

Билгеле булганча, диспансеризация узарга теләгән кеше иң элек үзе беркетелгән хастаханәгә барып терапевтка мөрәҗәгать итәргә тиеш. Алга таба ул табиб кушкан анализларны тапшырып, үз яшенә билгеләнгән тикшеренүләрне уза (таблицада. – **Д.Г.**). Тикшеренү барышында хилафлыклар табылса, кеше тар белгечләргә җибәрелә. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының баш онкологы Эдуард Нагуманов сүзләренә караганда, күпләр диспансеризациянең менә шушы икенче өлешен үтеп бетерми икән.

– Яман шеш ихтималы дигән сүзне ишетүгә кеше аеруча куркып кала. Тикшерү барышында ниндидер хилафлыклар күзәтелгән кешеләрнең 30–35 проценты алга таба тикшеренүдән баш тарта. Еш кына аларның ни өчен болай эшләвен үзебез дә аңлап бетермибез, – ди белгеч.

Бүген Татарстанда элеккечә үк тире, эчәклек, сөт бизе яман шеше киң таралган. Диспансеризация исә барлык төр яман шешләрнең яртысын ачыкларга ярдәм итә, ди белгечләр. Аерым алганда, диспансеризация программасы кысасында каралган скрининг технологияләре ярдәмендә сөт бизләре, аналык муеннтыгы, мәни бизе, эчәклек яман шешен 1–2 стадиядә чакта ук ачыкларга мөмкин.

– Яман чир вакытында сызлау, авырту кебек билгеләр чир инде яхшы ук азган мәлдә генә сизелә башлый. Шуңа күрә хәлне соң чиккә җиткермәс өчен диспансеризация кебек профилактик чараларда катнашырга, чирне башлангыч чорда ук ачыкларга кирәк. Бүген безгә мөрәҗәгать итүчеләрнең күбесе – менә шушы тикшеренүләргә бармак аша караган, авыруны азындырганчы йөргән кешеләр. Андый чакта инде без дә әллә ни ярдәм итә алмыйбыз, – ди Эдуард Нагуманов.

Бөер игътибар көтә

Саба районының Олы Шыңар авылында быел 174 кеше диспансеризация узарга тиеш булган. Шуларның 113е бу тикшеренүне үткән инде. 700ләп кеше яшәгән авылның фельдшер-акушерлык пункты фельдшеры Рузилә Мөхәммәтова сүзләренә караганда, тиздән районга Казаннан күчмә маммография машинасы кайтачак. Авыл халкының калган өлеше диспансеризацияне әнә шул көннәрдә узар дип планлаштыралар.

– Соңгы арада халык диспансеризациягә бик теләп йөри. Бигрәк тә тизәктә яшерен кан булу-булмауны тикшерә башлагач, аны узарга теләүчеләр саны артты. Кеше берни дә борчымаса, тик торганда табибка барып, эчәкләрен тикшертеп йөрми бит инде. Ә бу анализ ярдәмендә эчәклектәге бик күп хилафлык, авыруларны ачыкларга, аларны яман шеш дәрәҗәсенә җиткермичә, вакытында дәвалый башларга мөмкин. Әлеге анализ ярдәмендә соңгы ике елда ике кешенең эчәклегендә башлангыч стадиядә яман шеш барлыгы ачыкланды. Шушы ук тикшеренү ярдәмендә күпләрдә полип, геморрой кебек чирләр барлыгы да билгеле булды. Бәхеткә, аларны да вакытында дәвалауга керештек, – ди фельдшер.

Камиллеккә чикләр юк, билгеле. Рузилә Мөхәммәтова да диспансеризациягә тагын берничә төр тикшеренү кертелсә, яхшы булыр иде дип саный. Аерым алганда, бавыр-бөерләрне җентеклəбрәк тикшерү яклы ул.

– Диспансеризация вакытында тапшырыла торган биохимия анализларында, нигездә, глюкоза белән холестерин гына тикшерелә. Диспансеризация программасына бавыр, бөерләрне тикшерә торган анализларны кертсәләр дә яхшы булыр иде. Аларда чир күбесенчә 40 яшьтән соң килеп чыга бит. Шуңа күрә кырыктан узганнарның әлеге органнарын УЗИдан тикшерү дә артык булмас иде, – ди белгеч.

Баулы районының Мортаза авылы фельдшеры Рәзинә Мөгинова да соңгы арада халык үзенең сәламәтлегенә игътибарлырак була башлады дип саный. Аларда диспансеризацияне быел узарга тиешле 125 кешенең 91е үткән.

– Бездә күбрәк өлкәннәр яши. Маммография аппараты үзебездә – Баулы хастаханәсендә булгач, бик уңайлы. Чиратка яздырам да, барып үтәләр. Быелгы диспансеризация барышында күбесенең шикәре югары булды. Эндокринологка җибәреп, учетка куйдык. Анализ нәтиҗәләре белән үзләре дә кызыксыналар. «Ватсап»ка язып, сорап торалар. Диспансеризация кертелгән генә елларда УЗИ да уздыралар иде. Ул хәзер дә артык булмас иде, – ди фельдшер.

НИЧӘ ЯШЬТӘ НИНДИ ТИКШЕРЕНҮ УЗАСЫ?

Тикшеренү	Яшь аралыгы		
	18–39 яшь	40–64 яшь	65 яшьтән өлкән
Анкета тутыру	елга 1 тапкыр / барлык категорияләр өчен		
Кан басымын, буйны, гәүдә авырлыгын үлчәү	елга 1 тапкыр / барлык категорияләр өчен		
Флюорография	2 елга бер тапкыр / барлык категорияләр өчен		
ЭКГ	Беренче тапкыр диспансеризация узганда; 35 яшьтән соң – ел саен	2 елга 1 тапкыр	
Күз басымын үлчәү	Беренче тапкыр диспансеризация узганда	Елга 1 тапкыр	
Акушер-гинеколог	Елга 1 тапкыр / барлык категорияләр өчен		
Терапевт	3 елга 1 тапкыр	Елга 1 тапкыр	
Кан анализы: гомуми, шикәр, холестерин	Елга 1 тапкыр / барлык категорияләр өчен		
Маммография		2 елга бер тапкыр/ 40–75 яшьтәге хатын-кызлар	
Тизәктә яшерен кан булу-булмауны ачыклаучы анализ		40–64 яшьтә – 2 елга 1 тапкыр, аннан соң ел саен	
Простатит антигенына анализ (ПСА)		5 елга 1 тапкыр / 45–64 яшьлек ир-атлар	



Истә тот!

✓18–39 яшь аралыгында диспансеризацияне өч елга бер тапкыр (18, 21, 24, 27, 30, 33, 36, 39 яшьтә), 40 яшьтән соң ел саен узарга кирәк.

✓Россия Хезмәт кодексының 185.1 маддәсе нигезендә, эш бирүче диспансеризация узган өчен түләнә торган ял көне бирергә тиеш. 40 яшьтән өлкәнрәк хезмәткәрләргә ул елга бер тапкыр, пенсия һәм пенсия алды яшендәге хезмәткәрләргә елга ике көн, калган хезмәткәрләргә өч елга бер тапкыр бирелергә тиеш. Бу ял көнен алу өчен, эш бирүче белән диспансеризация узачак көнне килештереп, гариза язарга кирәк. Бу көнне дөрестән дә табибта булуыгызны исә хастаханәдән алынган белешмә ярдәмендә расларга туры киләчәк.

Эльвира
ВӘЛИЕВА

БЕР ЙОТЫМ АГУ

Илдар Мөхәммәтҗанов

30дан артык кеше үлде, зыян күрүчеләр 100гә якынлаша. Теракт, зур янгын яки транспорт фаҗигасе түгел, аз алкогольле «Мистер Сидр» эчемлегеннән агуланучылар бу. Куркыныч хәлләр күрше төбәкләрдә килеп чыкты. Тагын да аянычлысы шул: агулы эчемлекне кибеттә сатканнар. Димәк, куркыныч теләсә кемгә яный? Татарстанда вазгыять ничек? Хәмер сөременнән агуланганнар айнырмы? «ВТ» хәбәрчесе әнә шул сорауларга җавап эзләде.

«Бездә сатмыйлар»

Татарстан янәшәсендәге төбәкләрдән бу көннәрдә хәмердән агуланып үлү очраклары турында хәбәрләр ишелде. Соңгы мәгълүматларга караганда, Самарада җитештерелгән «Мистер Сидр» алкоголь эчемлегеннән 30дан артык кеше үлгән, тагын 100гә якыны зыян күргән. Ульян өлкәсендә генә дә 20 кешенең гомере өзелде, тагын 60тан артыгын хастаханәгә салганнар. Үлем һәм зыян күрү очраклары Самара, Удмуртия, Чуашстан, Түбән Новгород, Пенза өлкәләрендә дә бар. Хастаханәгә эләгүчеләрнең иң яшенә нибары 14 яшь. «Роспотребнадзор» башлыгы Анна Попова әлеге эчемлекне сатудан алырга кушты. Аны җитештергән эшмәкәрне кулга алдылар. Хәзергә тикшерүләр бара. Димәк, «Мистер Сидр» гына түгел, куркыныч башка эчемлекләр дә табылырга мөмкин әле.

Күпфатирлы йортларның беренче катында урнашкан аз градуслы хәмерне зур мичкәләрдән агызып сатучы кибетләргә, яшьләр арасында аларны «разливайка» дип йөртәләр, ияләшеп беттек кебек. Бүген адым саен диярлек сыралы эчемлек тәкъдим итәләр. Интернет мәгълүматларга ышансаң, Казанда гына да 850гә якын алкоголь сатучы сәүдә ноктасы бар. Чагыштыру өчен, шул ук чыганаклар буенча башкалада даруханәләр саны 1 мең тирәсе.

Казан кибетләрендә агулы эчемлек сатмыйлармы дип, «ВТ» хәбәрчесе дә үзе яшәгән Иманлек урамы тирәсендәге «разливайка»ларга сугылды. Өйдән биш минутлык арада шундый дүрт хәмер сату ноктасы бар булып чыкты.

– Самара сидры бармы? – дип сорыйбыз сатучыдан.

– Бу көннәрдә кергән бер кеше шул сорауны бирә, – ди үзен Анна дип таныштырган сатучы, елмаеп. – Борчылмагыз, бездә андый җитештерүченең булганы да юк.

Сорау – җавап

Лицензияле кибетләргә легаль булмаган хәмер эләгергә мөмкинме?

Рөстәм АРСЛАНОВ, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе урынбасары:

– Юк, эләгә алмый. Татарстанга хәмер кертү белән шөгыльләнүче күпләп сату предприятиеләре үз ихтыяры белән бөтен продукциясене тикшертә. Татарстан Дәүләт алкоголь инспекциясе белгечләре зур градуслы хәмернең сыйфатын, шулай ук җитештерелүе, әйләнештә йөртелүенең законлы булу-булмавын тикшерә. Тикшерү нәтиҗәләре буенча һәр шешәгә махсус стикер яки теркәү номеры сугыла. Алар продукциянең легальлеген раслый. Теге яки бу хәмернең законлы сатылу-сатылмавын кибеттә үзең үк, федераль махсус яки акциз маркаларын сканер аппаратына куеп, тикшереп карарга мөмкин.

Гомумән, Самара эчемлекләрен сатмыйбыз. Ышанмасагыз, документларны күрсәтәм. Без – зур сәүдә челтәре. Ышанычлы товар тәэмин итүчеләр белән генә эшлибез. Бөтен алкоголь эчемлекләр тикшерү уза, ЕГАИС системасында теркәлә.

Сөйләгәннәрен дәлилләп, өстәлгә кызыл папкага тупланган документлар да чыгарып куйды ул.

– Бездә Белоярск шәһәрендә җитештерелгән сидр гына бар. Манго тәме килә торганының бер литры 137 сум тора, – диде сатучы, шул арада эчемлекне мактап алырга да өлгереп.

Икенче бер сәүдә ноктасында алкоголь эчемлекләргә документларны сорагач:

– Тагын тикшерүме әллә? – дип куркуга ук калдылар.

Баксаң, билгеле хәллләрдән соң аларны Татарстан Дәүләт алкоголь инспекциясе белгечләре әнә күзе аша үткәрә башлаган икән.

– Татарстандагы кибет киштәләрендә «Мистер Сидр» юкмы, булса, сатудан алырга, дигән фәрман бирделәр. Барлык документларны тикшерделәр. Бездә андый эчемлек сатылмый. Кирәк булса, җитәкчегә шалтыратам, ул сезгә телефон аша аңлатма бирәчәк, – диде сатучы.

Сатудагы сидрның кайда җитештерелүен сораша башлагач: «Барлык документлар да төп офиста саклана. Шуннан артыгын әйтә алмыйм. Мин монда ике-өч көн генә эшлим әле», – дип чикләнде.

Татарстан Дәүләт алкоголь инспекциясенең матбугат хезмәтеннән алынган мәгълүматларга караганда, республикада аз градуслы «Мистер Сидр» алкоголь эчемлеге юк. «Ведомство алкоголь базарында катнашучыларның декларацияләрен, ЕГАИС мәгълүматларын тикшерде. Нәтиҗәдә Татарстанга мондый алкоголь эчемлек һәм, гомумән, «Анди» ҖЧҖ продукциясе кертелмәве расланды», – диелә хәбәрдә.

Актанышка кирәкми

Тик тынычланырга иртәрәк. Татарстан Дәүләт алкоголь инспекциясе мәгълүматларына караганда, республикада алкоголь эчемлек куллану күрсәткече арта. Быелның гыйнвар – апрель айларында хәмер сату күләме, узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, тагын 3 процентка арткан. Бу – соңгы ун елда иң зур күрсәткеч, ди белгечләр. Шунысы да бар: аракы сату күләме берникадәр кимегән. Димәк, башкасына өстенлек бирәләр.

«Яшәү өчен» социаль инициативалар берлегенең клиник психологы Арина Байтимерова фикеренчә, соңгы арада дөньяда, илдә барган вакыйгалар күпләрнең тормышын астын өскә китерде.

– Башта пандемия аркасында билгесезлеккә чумдык. Күпме кеше эшсез калды, иртәгәге көнгә ышанычын югалтты. Коронавирус бетте дигәч кенә махсус хәрби операция башланды. Чүп өстенә чүмәлә: сентябрьдә мобилизация игълан иттеләр. Болар барысы да җәмгыятьтәге киеренкелекне арттырды. Ә стресс булган җирдә хәмер куллану күрсәткече дә арта. Шул рәвешле аз булса да онытылырга телиләр. Тик нәтиҗәсе аяныч тәмамланырга мөмкин, – ди белгеч.

Былтыр республикада 5,84 мең декалитр (1 декалитр = 10 литр) исерткеч эчемлек сатылган. Алдагы ел белән чагыштырганда, әлеге күрсәткеч 4 процентка арткан. Хәмер сатып алучылар республиканың барлык районнарында да күбрәк теркәлгән. Барыннан да бигрәк, Кайбыч районында (+24%) яшәүчеләр уздырган. Күрсәткечләр Югары Ослан, Чүпрәле һәм Яңа Чишмә районнарында да (һәркайсында +20%) сизелерлек арткан. Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә былтыр 4 процентка күбрәк спиртлы эчемлек сатылган. Әлки районында хәмер сату күләме узган ел дәрәҗәсендә калса, бердәнбер Актанышта әлеге күрсәткеч 3 процентка кимегән.

Республикада яшәүче һәр кешегә, әби-бабайларны һәм яңа туган балаларны да кертеп, 15 литр хәмер (сыра исәпкә алынмаган) туры килә, ди белгечләр. Бу яктан иң зур күрсәткечләр Югары Осланда (22,6 литр) һәм Лаешта (19,4 литр) теркәлгән. Аксубай (7,3 литр), Чүпрәле (8,2 литр), Спас (8,6 литр) һәм Тәтеш районнарында (9,4 литр) бер кешегә иң аз күләмдә хәмер туры килгән.

Аз градуслы спиртлы эчемлекләргә килгәндә, узган ел республикада 55 миллион декалитр сыра җитештерелгәннәр. Чаллыда яшәүчеләр генә дә былтыр 40 миллион литр сыра эчкән. «Алдагы ел белән чагыштырганда, бу 1 процентка азрак, – ди Дәүләт алкоголь инспекциясенең Чаллы территориаль органы җитәкчесе Гөлшат Вафина. – Бер ел эчендә республика бюджетына алкоголь эчемлекләр сатудан 24,4 миллиард сум акча кергән. Шуның яртысы – сыра продукциясен сатуга туры килгән».

Күрше хакы

Эчүчеләр булганда, бу юл белән акча эшләргә теләүчеләр дә табылачак, әлбәттә. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының матбугат хезмәтеннән алынган мәгълүматларга караганда, ел башыннан бирле хокук саклаучылар 15 мең литр алкоголь һәм спирт продукциясен законсыз әйләнештән алган. Барлыгы 44 җинаять һәм 444 административ хокук бозу очрагы ачыкланган. Мәсәлән, Балык Бистәсендә кибет хуҗасы аракыны документларсыз гына саткан. Мөслим районында бер хатын-кыз өйдә «бизнес» ачкан. Хокук саклаучылар шәхси хуҗалыкта 178 литр спиртлы продукциягә тап булган. Чаллыда яшәүче ир-ат исә бакчачылык ширкәтеннән сәүдә нокталарына ялган алкоголь эчемлекләр тарату эшен җайга салган. Яшереп хәмер сату очраклары Яшел Үзән һәм Югары Ослан районнарында да ачыкланган. Ялган аракыны нигездә шикле сәүдә нокталарында һәм кулдан саталар, ди белгечләр. Былтыр Татарстанга контрафакт продукцияне күбрәк Башкортстан, Самара һәм Удмуртиядән алып кергәннәр.

Рәсми мәгълүматларга караганда, былтыр Татарстанда 609 кеше сыйфатсыз хәмер белән агуланган. Нәтиҗәдә 218 кешенең гомере өзелгән. Алдагы ел белән чагыштырганда, бу 8 процентка күбрәк. Республиканың 12 районында сыйфатсыз хәмер белән агуланучылар күрсәткече республика күләмендәге уртача саннардан да зуррак.

Белгеч сүзе

Рөстәм ВӘЛИУЛЛИН, табиб-нарколог:

– Өч дистәдән артык кешенең үлеменә китергән әлеге бәхетсезлек очрагы этил спирты урынына метил спирты куллануга бәйле дип саныйм. Ә метил спирты – ул сулау-нерв системасының эшен туктатучы нейротоксинлы агу. Үлемгә китерү өчен 30–50 грамм, хәтта моннан да азрак хәмер эчү дә җитә. Метил спирты белән агулануның төп билгеләре: күз күрми башлый, укшыта, костыра. Кеше аңын югалтып егылырга да мөмкин. Ул үзенең кайдалыгын аңламый башлый, хәтере чуала һәм сулышы туктый. Шунысы да мөһим: соңгы елларда яшьләр арасында нәкъ менә аз градуслы эчемлекләр кулланучылар саны артуы күзәтелә. 40 елга якын тәҗрибәмнән чыгып шуны да әйтәсем килә: берьюлы бу кадәр күп кешенең агулануын тәүге тапкыр күрәм. Миңа моңарчы да метил спирты белән агуланучылар белән очрашырга һәм эшләргә туры килгәне бар. Аларның берсе дә исән калмады. Бу – бик авыр һәм катлаулы дәвалау эше, андый кешене тормышка яңадан кайтару мөмкин түгел диярлек.

12 июнь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
08.00 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». Телесериал 16+
10.00, 23.30 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». Телесериал 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.35 «СЕБЕР КИЯВЕ». Телесериал (на татарском языке) 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.30 «История побед. КамАЗ-мастер». Специальный репортаж Алины Сулеймановой 12+
15.00 «СОКРОВИЩА ЕРМАКА» 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
19.00, 20.00, 21.00 Праздничный концерт, посвящённый Дню России 0+
19.30, 22.05 Новости Татарстана 16+
00.25 «Соотечественники». Просвещенья век 16+
00.50 «Таяну ноктасы» 16+
01.15 «Каравай» 6+
01.40 «Татар халык җырлары» 0+
02.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Аулак өй» 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.10, 04.15 «Башваткыч» 12+
11.00, 17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05 «Музыка елгасы». Ренат Еникеев турында телеочерк 16+
15.00 «Заман көзгесе» 6+
15.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.05 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.35 «Адымнар» 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
18.00, 22.05, 00.00 «Яңалыклар» 16+
18.20 «Ватандашлар». Индус Таһиров. Халык илчесе 16+
19.00 Россия көненә багышланган бәйрәм концертыннан турыдан-туры трансляция 6+
22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
00.40 «Үткәннәр сагындыра» 12+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

06.00 Новости
06.10 «Символы России» 12+
07.00 «День России». Праздничный канал
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 Премьера. Специальный репортаж. «Кто, кроме нас» 16+
11.10 «Империя: Петр I» (S) 12+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Империя: Петр I» (S) 12+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 «Империя: Петр I» (S) 12+
15.50 Премьера. Гала-концерт Всероссийского музыкального патриотического фестиваля «Своих не бросаем» (S) 12+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
19.10 «МИХАИЛ ЗАДОРНОВ: МЫСЛИ И ПРЕДСКАЗАНИЯ» (S) 16+
21.00 «Время»
22.35 «Что? Где? Когда?» Летняя серия игр (S) 16+
23.45 Россия от края до края. Премьера. «Женщины Алтая» 12+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
01.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
02.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
02.50 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
03.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+
04.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+

РОССИЯ 1

05.20 Елена Валюшкина, Елизавета Арзамасова, Артём Крылов, Кристина Бабушкина, Алексей Шевченков, Владимир Стержаков. «УКРОЩЕНИЕ СВЕКРОВИ» 12+
07.15 Елена Валюшкина, Елизавета Арзамасова, Артём Крылов, Елена Бирюкова, Александр Мохов, Татьяна Журавлёва, Вадим Колганов, Алексей Шевченков, Людмила Полякова, Владимир Стержаков. «УКРОЩЕНИЕ СВЕКРОВИ. ПРОДОЛЖЕНИЕ» 12+
11.00, 13.00, 17.00, 20.00 Вести
12.00 Москва. Кремль. Церемония вручения Государственных премий Российской Федерации
13.30 Владимир Машков, Сергей Маковецкий, Владимир Меньшов, Михаил Пореченков, Светлана Крючкова, Константин Лавроненко. «ЛИКВИДАЦИЯ» 16+
18.00 Большой праздничный концерт, посвящённый Дню России. Трансляция с Красной площади
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Премьера. Виктор Хориняк, Сергей Безруков, Ангелина Стречина, Инга Оболдина, Евгения Дмитриева, Артур Ваха и Владимир Стержаков. «МИСТЕР НОКАУТ» 12+
23.30 Игорь Петренко, Иван Батарев, Мария Миронова, Сергей Губанов, Илья Носков в фильме «НЕБО» 12+
02.00 Антон Пампушный, Гоша Куценко, Милош Бикович, Равшана Куркова, Гойко Митич, Милена Радулович. «БАЛКАНСКИЙ РУБЕЖ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Легендарные клубы» 12+
06.30 «Здоровый образ. Баскетбол» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 18.55, 22.25 Новости
07.05, 13.00, 15.45, 21.20, 00.30 Все на Матч! Прямой эфир
10.05 «СНЕЖНЫЕ ДОРОЖКИ». Мультипликационный фильм 0+
10.15 «ШАЙБУ! ШАЙБУ!» Мультипликационный фильм 0+
10.35 «НУ, ПОГОДИ!» Мультипликационный фильм 0+
10.55 Мини-футбол. Чемпионат России. PARI-Суперлига. Финал. «Норильский Никель» (Норильск) – КПРФ (Москва). Прямая трансляция
13.55 Бокс. Кубок Победы. Прямая трансляция из Перми
16.25 «Валерий Харламов. На высокой скорости». Документальный фильм 12+
17.25 «Лето. Евро. 2008» 12+
17.55 «Громко». Прямой эфир
19.00 Футбол. Лига чемпионов. Финал. «Манчестер Сити» (Англия) – «Интер» (Италия). Трансляция из Турции 0+
22.30 «Вы это видели» 12+
23.30 Боулинг. Континентальная лига. Про-тур. Команды. Трансляция из Казахстана 0+
01.25 Бокс. Bare Knuckle FC. Кай Стюарт против Луи Лопеса. Трансляция из США 16+
02.55 Новости 0+
03.00 Баскетбол 3x3. Winline Чемпионат России. Трансляция из Сочи 0+
05.00 «Громко» 12+

НТВ

05.05 «Новые русские сенсации» 16+
06.00, 08.20 Евгений Сидихин, Александр Самойленко, Александр Назаров, Елена Валюшкина. «ЧАС СЫЧА» 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
10.20 «ПЁТР I: ПОСЛЕДНИЙ ЦАРЬ И ПЕРВЫЙ ИМПЕРАТОР» (S) 16+
13.25 Остросюжетный фильм «ОТСТАВНИК. СПАСТИ ВРАГА» (S) 16+
15.30, 16.20 Остросюжетный фильм «ОТСТАВНИК. ЗАЩИТА ДЕДОВА» (S) 16+
19.40 Премьера. Борис Галкин. «ОТСТАВНИК. БЛИЖНИЙ БОЙ» (S) 16+
23.00 Праздничный концерт, посвященный 12 июня (S) 12+
00.20 Михаил Полосухин. «ПОСЛЕДНИЙ ГЕРОЙ» 16+
02.15 «Три танкиста». Фильм Алексея Поборцева 16+
03.00 «Военно-исторические маршруты» 16+
03.25 Остросюжетный сериал «ПЕТЛЯ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «ЕВДОКИЯ» 16+
08.00 «ЗА БОРТОМ» 16+
10.15 «СТАРУШКИ В БЕГАХ – 2» 16+
19.00 «ИДЕАЛИСТКА» 16
23.30 «КАК ВЕРНУТЬ МУЖА ЗА ТРИДЦАТЬ ДНЕЙ» 16+
01.10 «ЕВДОКИЯ» 16+
02.55 «6 кадров» 16+
03.35 «СКАЖИ ТОЛЬКО СЛОВО» 16+

ЗВЕЗДА

05.50 «СКАЗ ПРО ТО, КАК ЦАРЬ ПЕТР АРАПА ЖЕНИЛ» 12+
08.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
08.20, 13.20, 18.20 «РОССИЯ МОЛОДАЯ». 1-я – 9-я серии 12+
22.35 «ЯРОСЛАВ» 16+
00.50 «ДЕМИДОВЫ» 12+
03.25 «Вещий Олег». Документальный фильм 12+

13 июнь | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». Телесериал 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «СЕБЕР КИЯВЕ». Телесериал (на татарском языке) 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
21.00 «Ватандашлар» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Каравай». Марийские музыкальные инструменты 6+
00.50 «Соотечественники». Зарисовки из жизни Хариса Якупова 16+
01.15 «Башваткыч» 12+
02.05 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Аулак өй» 6+
04.45 «Вечерняя игра» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.15 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30 «Заман көзгесе» 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Нәсыйхәт» 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате» 16+
13.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
15.25 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30 «Таяну ноктасы» 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
19.10, 22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
00.00 «Яңалыклар» 16+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 Премьера. «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 Юлия Снигирь в исторической драме «ВЕЛИКАЯ» (S) 12+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+
00.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Все хотят летать» 16+
01.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
02.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
02.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+
03.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Неформат» 16+
04.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Триггеры» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. «ВАЛЮША» 12+
23.55 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.40 Екатерина Климова, Александр Ратников, Евгений Пронин, Олег Алмазов. «МОСКОВСКАЯ БОРЗАЯ 2» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Легендарные клубы» 12+
06.30 «Наши иностранцы» 12+
07.00, 10.00, 12.40, 15.40, 18.55, 22.25 Новости
07.05, 14.55, 17.55, 21.30, 00.30 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 12.20, 02.35 Специальный репортаж 12+
10.25 «Короли. Из гетто к победе и золоту». Документальный фильм 12+
11.40 Профессиональный бокс. Эдуард Трояновский против Айка Шахназаряна. Трансляция из Москвы 16+
12.45, 15.45 Футбол. BetBoom МКС 2023. Прямая трансляция
19.00 «Зенит». Звёздная история» 12+
19.30 Футбол. Кубок УЕФА. Сезон 2007-2008. Финал. «Зенит» (Россия) – «Глазго Рейнджерс» (Шотландия). Трансляция из Англии 0+
22.30 Бильярд. Кубок мэра Москвы. Сборная России – Сборная мира. Трансляция из Москвы 0+
01.25 Классика бокса. Кассиус Клэй против Сони Листона 16+
02.20 Классика бокса. Мохаммед Али против Джорджа Формана 16+
02.55 Новости 0+
03.00 Баскетбол 3x3. Winline Чемпионат России. Трансляция из Сочи 0+
05.00 «Что по спорту? Тверь» 12+
05.30 «Андрей Аршавин меняет профессию» 12+

НТВ

04.55 Детективный сериал «МОСКВА. ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ОКРУГ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «За гранью» 16+
17.55 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Кирилл Зайцев, Максим Щеголев в детективном сериале «ЭФФЕКТ ДОМИНО» (S) 16+
22.15, 00.00 «РЕАЛИЗАЦИЯ» (S) 16+
01.55 «ЗНАКОМСТВО» 16+
03.25 Остросюжетный сериал «ПЕТЛЯ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «СКАЖИ ТОЛЬКО СЛОВО» 16+
06.45 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.00 «Давай разведёмся!» 16+
09.00 «Тест на отцовство» 16+
11.15 «Понять. Простить» 16+
12.30 «Порча». «Корыстный треугольник» 16+
13.00 «Знахарка» 16+
13.35 «Верну любимого» 16+
14.10 «Голоса ушедших душ» 16+
14.45 «МЕХАНИКА ЛЮБВИ» 16+
19.00 «РОКОВАЯ ОШИБКА» 16+
23.15 «Понять. Простить» 16+
00.30 «Порча» 16+
00.55 «Знахарка» 16+
01.20 «Верну любимого» 16+
01.45 «Голоса ушедших душ» 16+
02.10 «Тест на отцовство» 16+
03.50 «КАК ВЕРНУТЬ МУЖА ЗА ТРИДЦАТЬ ДНЕЙ» 16+

ЗВЕЗДА

05.00 «ПИРОЖКИ С КАРТОШКОЙ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 01.00 «ОШИБКА РЕЗИДЕНТА». «ПО СТАРОЙ ЛЕГЕНДЕ» 12+
12.25, 13.25, 15.05, 03.20 «ВОСХОЖДЕНИЕ НА ОЛИМП». 1-я и 2-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
15.20, 17.10 «ВОСХОЖДЕНИЕ НА ОЛИМП». 3-я и 4-я серии 16+
18.00 «Вторая мировая: пламя и сталь». «Бомбардировщики» 16+
18.50, 19.55 «Спецрепортаж» 16+
20.10 «Улика из прошлого» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «СЕМЕН ДЕЖНЕВ» 12+
02.15 «Александр Третий. Сильный, державный...» Док. фильм 12+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Дәүләт хакимияте органнарында нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең дәүләт бүләкләре бүлеге баш киңәшчесе **Хәсәнов** Айдар Фәрит улына **Татарстан Республикасы Рәисенең Рәхмәте** белдерелде.

* * *

«ГИГАНТ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең машина белән сыер саву операторы (Татарстан Республикасының Тукай районы) **Гәрәева** Елена Степановнага, «Чынлы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең машина белән сыер саву операторы (Татарстан Республикасының Чүпрәле районы) **Җаббарова** Зөлфия Мидхәт кызына, «АксуАгро» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте сыер савучысы (Татарстан Республикасының Аксубай районы) **Кудряшова** Валентина Ильиничнага, «Нурлат-Сөте» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең терлекләрне ясалма орлыкландыру буенча операторы (Татарстан Республикасының Нурлат районы) **Семенова** Антонида Геннадиевнага **«Татарстан Республикасының атказанган терлекчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Магнолия-С Чаллы металл кою-механика заводы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Майоров** Сергей Васильевичка **«Татарстан Республикасының атказанган машина төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«ГИГАНТ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры урынбасары (Татарстан Республикасының Тукай районы) **Галиуллин** Рөстәм Рафис улына, «Россия авыл хуҗалыгы үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы Лениногорск район бүлеге башлыгы **Ганеев** Марат Магарип улына, «ОРСИС-АГРО» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте бухгалтериясе баш бухгалтерының бухгалтерлык исәбе буенча урынбасары (Татарстан Республикасының Түбән Кама районы) **Долгова** Луиза Сергеевнага, «Нур Баян исемендәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте инженеры (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Ибраһимов** Мөхәмәтнур Рафаел улына, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитештерү бүлеге өлкән белгече **Миңдубаев** Рөстәм Госман улына, «Август-Мөслим» ашлык кабул итү предприятиесе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең орлык киптерү линиясе булган ашлык киптерү комплексы мөдире (Татарстан Республикасының Мөслим районы) **Мөхәммәтдинов** Рәсим Миркасыйм улына, «Яңарыш» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш бухгалтеры (Татарстан Республикасының Арча районы) **Сабирова** Вәсилә Нурислам кызына, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы **Сәлимгәрәев** Нәфис Әзгам улына, «Восток агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте әйдәүче агрономы (Татарстан Республикасының Зәй районы) **Тугашев** Николай Романовичка, «Кармалы» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (Татарстан Республикасының Түбән Кама районы) **Фәзуллин** Илнур Вилсур улына, «Яңарыш» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш инженеры (Татарстан Республикасының Арча районы) **Фарухов** Альбирт Зиннәт улына, «Лаеш районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе баш бухгалтеры **Фатыйхова** Ания Мөхәммәтхатыйп кызына, «Нәҗар» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш бухгалтеры (Татарстан Республикасының Әгерҗе районы) **Харисова** Диларә Рафаил кызына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«ЮВТ АЭРО» акционер җәмгыяте техник директоры **Реутов** Василий Владимировичка, «Россия тимер юллары» ачык акционер җәмгыяте филиалы – Үзәк элемтә станциясе структур бүлекчәсе – Түбән Новгород элемтә дирекциясе структур бүлекчәсе – Казан төбәк элемтә үзәге башлыгы **Хуснутдинов** Руслан Гусман улына, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы гомуми бүлеге автомобиль йөртүчесе **Шәйхетдинов** Илгизәр Әскәр улына **«Татарстан Республикасының атказанган транспорт хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе, әтисе

ПРИВАЛОВ Анатолий Витальевич

вафат булу сәбәпле, Казан (Идел буе) федераль университетының Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе директоры Привалов Игорь Анатольевичның авыр кайгысын уртаклаша.

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе,

әтисе

кинәт вафат булу сәбәпле, Казан (Идел буе) федераль университетының Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе директоры Привалов Игорь Анатольевичның авыр кайгысын уртаклаша.

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе,

әнисе

кинәт вафат булу сәбәпле, Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутаты Кәлимуллин Рөстәм Галиулла улының авыр кайгысын уртаклаша.

Бу авыр көннәрне кичерергә сабырлык, ныклык бирсен.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

СЫТКАННЫ ЯРАТМЫЙ

Комедон, акне, папула... Без бетчә дип атап йөрткән «дошман»ның әнә шундый төрләре бар. Берәүләрнең битендә бетчәләр вакытлы гына күренеш булса, икенче берләре гомер буе шулар белән көрәшеп яши. Ничек кенә булмасын, бетчә чыгу – кешегә шактый зур уңайсызлык тудыра торган күренеш. Аларны кисәтеп, бетчәләрдән тиз генә котылып буламы? Алар нинди авырулар турында кисәтә?

vk.com

Косметолог Эльвира МАРКОВА белән шул хакта сөйләштек.

:: Күпләрнең үзегенә үткән бетчәләр нидән гыйбарәт?

– Чәч төкләре нигезендә яткан май бизләре тән тиресен саклый, аны корылыктан коткара. Әгәр ул чамадан тыш күп бүленеп чыга башласа, тәндә бетчәләр пәйда була. Ялкынсынган һәм ялкынсынмаган бетчәләр була. Әйтик, комедон дигән төре бар. Ачык комедон – кара башлы бетчәләр. Май бизләре кислород белән ачу тәэсирендә пәйда була. Ябык комедон – төер формасындагы бетчәләр. Анда кислород үтеп керә алмый. Алар белән эшләве авыррак.

:: Бетчәләр ни сәбәпле пәйда була?

– Битендә бетчәләре булган кеше косметологка гына түгел, дерматологка да мөрәҗәгать итәргә тиеш. Ник дигәндә, бетчәләр тире авыруларының бер билгесе дә булырга мөмкин. Организмда стафилококк, стрептококк кебек бактерияләр булганда да бетчәләр пәйда була ала. Еш кына алар эндокрин системасы, ашказаны-эчәк системасы (гастрит, язва һ.б.) эшчәнлеге бозылу турында да кисәтә. Стресслар, артык баллы ашау аркасында, күрем алдыннан да тән тиресен, бигрәк тә битне бетчә баса. Яшүсмерләрнең дә үзегенә үткән проблема бу. Бүген һәр ике үсмернең берсе битендәге бетчәләрдән котыла алмый тилмерә. Моңа аларның дөрес тукланмавы, фастфуд, газлы су кебек зарарлы ризыкларга өстенлек бирүе сәбәпче. Күчеш чорында аларның организмы болай да гормональ яктан зур үзгәреш кичерә. Моңа әле шушы дөрес тукланмау да килеп өстәлә. Бетчәләр нәселдән-нәселгә дә күчә ала. Алар тән тиресен дөрес тәрбияләмәү аркасында да пәйда булырга мөмкин.

:: Бетчәләрне сытарга ярыймы?

– Аларны сытарга киңәш ителми. Ник дигәндә, аннан соң биттә еш кына эзләр кала. Шуңа күрә бу эшне тәҗрибәле белгечкә тапшырсаң хәерлерәк.

:: Ә кайсы бетчәләрне сыту, гомумән, тыела?

– Башы булмаган, кызыл бетчәләрне бөтенләй сытарга ярамый. Болай эшләгәндә тән тиресенең бу өлешендәге ялкынсыну көчәячәк кенә. Өстәвенә, мондый бетчәләрне теләсә ничек сытканда, моны кулларны юмаган килеш эшләгәндә ялкынсынган бетчәгә инфекция дә эләгергә мөмкин.

:: Кояш бетчәләрдән котылырга ярдәм итә, диләр. Бу сүзләрдә хаклык бармы?

– Бу фикер белән килешмим. Кояш нурлары, киресенчә, бетчәләрне тагын да азындырырга мөмкин. Ник дигәндә, бит тиресе кояшта тирли, нәтиҗәдә ул, үзүзен саклау өчен, май бизләрен тагын да күбрәк бүлеп чыгара башлый. Шул рәвешле биттә яңадан-яңа бетчәләр пәйда була. Дөрес, диңгез буенда, әйтик, шул ук Кырымда кояш нурлары, киресенчә, бит тиресенә бик файдалы. Ул күп кенә тире авыруларын дәвалауга сәләтле. Шуңа күрә анда яшәүчеләр бетчәләрнең нәрсә икәнен дә белми.

:: Бетчәләр пәйда булу кешенең җенси тормыш белән яшәү-яшәмәвенә бәйлеме?

– Бу сүзләрдә күпмедер дәрәҗәдә хаклык бар. Ник дигәндә, бетчәләр җенси гормоннарга да бәйле. Үсмер чакта гормоннар дөрес эшләми. Организм зур стресс кичерә, нәтиҗәдә биттә бетчәләр пәйда була. Кеше үсә төшеп, даими рәвештә җенси тормыш белән яши башлагач, гормоннар инде тынычлана төшә, көйле эшли башлый. Шул рәвешле бетчәләр дә юкка чыга, тән тиресе дә яхшыра.

Ничек котылырга?

1 Иң элек косметологка, дерматологка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Ул бетчәләрнең ни сәбәпле пәйда булганын ачыклап, тиешле дәвалау курсы билгеләячәк.

2 Бетчәләрне кисәтү, алардан котылу өчен бит тиресен яхшылап, дөрес итеп чистартырга да кирәк. Аерым алганда, составында спирт булган чистарткыч чаралар, лосьоннар белән мавыгырга ярамый. Алар бит тиресен бик нык корыта. Шуңа күрә аларның составында салицил, азелаин кислотасы, В витамины булган төрләренә өстенлек бирергә кирәк.

3 Битне көнгә ике тапкыр – иртә-кич кенә чистартырга кирәк. Шуннан да артыгы ярамый. Атнага бер тапкыр пиллинг ясау да файдага булачак.

4 Бетчәләрдән котылам дисәң, баллы, ачы ризыклардан да баш тартырга кирәк. Йокыны туйдыру да мөһим.

Саклап куй!

ФАЙДАЛЫ БИТЛЕКЛӘР

1 рецепт. Бетчәләр еш чыга торган биткә солы битлеге килешә. Моның өчен 1 аш кашыгы солы лачаулары на куе ботка хасил булганчы кайнар су өстәргә кирәк. Суынгач, шуны биткә сөртеп, кипкәнче тотасы. Аннан бүлмә температурасындагы су белән юарга кирәк. Бу битлекне атнага 2–3 тапкыр ясасагыз, битегез чистарыр.

2 рецепт. 25 г төссез кынага (хна буявы) 2 аш кашыгы зәйтүн мае салып, бертөрле масса хасил булганчы болгатыгыз. Биткә түгәрәк хәрәкәтләр белән сөртегез дә 10 минут көтегез. Аннары су белән юып төшерегез. Әлеге битлек 1–2 атнага җитә.

3 рецепт. Банан да җыерчыклардан һәм бетчәләрдән котылырга булыша. Өч кенә ингредиенттан торган әлеге битлек тә биткә икенче сулыш бирә. Бик тиз эшләнә дә. Бер бананны изеп, 1 аш кашыгы каймак һәм йомырка сарысы кушып, әлеге катнашманы биткә сөртегез. Битлекне биттә 10–15 минут тотып, җылы су белән юыгыз.

Киңәш-табыш

Тупыл мамык койганда...

Тупыл мамык койган чак... Күпләр бу чорда аллергиядән интегә. Күзләр кызара, йөткертә, төчкертә башлый... Тупыл мамыгыннан ничек сакланырга?

✓ Тупыл мамык койган чорда гүзәл затларга аеруча игътибарлы булырга кирәк. Бу көннәрдә йөзгә тональ крем сөртүдән тыелып тору хәерле. Болай эшләгәндә тупыл мамыгы биткә ябышмаячак.

✓ Кояш күзлеге күзләрне кояш нурларыннан гына түгел, тупыл мамыгыннан да саклый.

✓ Тупыл мамык койган чорда күзләргә линза кимәсәң яхшырак. Ник дигәндә, линза астына мамык эләксә, аны тиз генә чыгарам димә. Куллар аша күзгә пычрак та эләгергә мөмкин.

✓ Урамнан кергәч, бит, борын, күзләрне яхшылап юарга онытмагыз.

✓ Көндезге сәгать 11дән кичке сәгать алтыга кадәр тупыл мамыгы аеруча нык оча. Көн җылына барган саен өскәрәк күтәрелә бара ул. Шуңа күрә аллергиядән интеккән кешеләргә бу сәгатьләрдә урамда йөрмәү хәерле.

Исеңдә тот!

Черки тешләп интектерсә

БОЗ. Черки тешләгән урын гадәттә кызыша башлый. Ник дигәндә, организм үзенә эләккән инфекциягә каршы көрәшә башлый. Боз әнә шушы черки тешләгән урындагы кычыту, кызышуны баса, шешне кимётә. Моның өчен бозны яулыкка төреп, 10–15 минутка черки тешләгән урынга куеп торырга кирәк.

СОДА. Ярты стакан суга бер чәй кашыгы сода салып эретәбез. Бинт яки мамыкны шушы эремәгә манып, черки тешләгән урынга куеп торабыз. Тәндә андый урыннар күп булса, бөтен гәүдәне шушы эремә белән усаң да була.

СЕРКӘ. 1/3 стакан суга бер аш кашыгы 9 процентлы серкә салып болгатабыз. Черки тешләгән урыннарны шушы катнашма белән эшкәртәбез. Серкә составындагы кислота кычытуны баса. Черки тешләгән урын кызармый.

КАЙМАК. Сөт ризыклары черки тешләгән урынны тынычландыра, кычытуны баса. Моның өчен кычыткан урынга каймакны кипкән саен сылап торырга кирәк.

ПАКЕТЛЫ ЧӘЙ. Чәй пакетына кайнар су агызып, суытабыз. Шуны черки тешләгән урынга 10–15 минутка куеп торабыз. Чәй составындагы танин дигән матдә черки тешләгән урынны ялкынсынудан саклый, кычытуны баса.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА

ҮРМӘЛЕ РОЗАНЫҢ СЕРЕ БАР

Берничә укучыбыздан бер үк сорау килеп иреште. «Үрмәләп үсә торган (плетистая) розаны ничек үстерергә? Нигә чәчәк атмый, шул хакта яза алмассызмы икән?» – дигәннәр алар.

Бик күп еллар розаларның төрле сортларын үстереп, тәҗрибә туплаган бакчачы-журналист Роза НУРГАЛИЕВА белән укучыларыбызны борчыган сорауга җавап эзләдек.

:: Розаның үрмәләп үсә торган төренең чәчәк атмавы нидән булырга мөмкин?

– Үрмәле розаның чәчәк атмавына дөрес кисмәү сәбәпче булырга мөмкин. Букетка киселә торган, мәсәлән, чайная роза, бер еллык ботакларда чәчәк ата. Кышын өшесә дә, каралган урыннарын кисеп ташлыйсың да, аннары җәй уртасына кадәр чәчәктә утырачак. Ә үрмәли торган розаны беренче елны көзен бөтенләй кисмиләр. Икенче елны кыскарталар гына. Чөнки бу төр розаның күбесе узган елгы ботакларында гына чәчәк ата. Кальнайган, өч елдан картрак ботакларын гына кисәргә, яшь ботакларын 2–3 бөрегә кыскартырга гына кирәк.

:: Ашламаны тиешенчә кертмәү дә аның чәчәк атмавына сәбәпче була алам ы?

– Чәчәк атмавының тагын бер сәбәбе азотлы ашламаларны чамасыз кертү дә булырга мөмкин. Чөнки бу очракта үл буйга нык үсә. Шулай ук дым күп булганда, артык күләгә урынга утыртканда чәчәк атмый торган сукыр ботакларын гына үстерергә һәм чәчәк күрсәтмәскә мөмкин.

Азотлы ашламаны (1 чиләк суга 1 аш кашыгы) иртә язда бер тапкыр сибәм. Аннан 2–3 атнадан соң тагын бер тапкыр тирес әчеткесе кулланам һәм розалар өчен чыгарылган махсус ашламаларга күчәм.

:: Безнең климатка туры килә торган сортларын сайлый белү дә мөһимдер...

– Үрмәле розаның нык киселмәвен исәпкә алып, безнең төбәккә яраклашкан сортларын утыртырга тырышыгыз. Миндә «Фламментанц» сорты үсә. Ул бер тапкыр, июнь ахырыннан июль ахырына кадәр чәчәк ата. Аннан кышка әзерләнә башлый. Аны тәҗрибәсе азрак кешеләр дә үстерә ала. Ул кышка үзе әзерләнеп керә. «Джон Кэбот» – Канада розасы, суыкларга бирешми. Ул – кабат чәчәк ата торган сорт, көзгә кадәр чәчәктә утыра. «Розариум ютерсен» кечкенә әле, алсу чәчәкле. Быел «Ясминә» дигән сортны утырттым. Анысын исемен татарчага охшаган булганга сайладым. Соңгы ике сорт әле сынала гына.

«Фламментанц», «Ясминә», «Симпатия»не Чиләбедәге «Сады России» интернет кибетеннән алдым. Урал климаты безгә туры килә, шуңлыктан әлеге сортлар бездә дә рәхәтләнеп үсә. "Джон Кэбот"ны "Дачный мир"дан алдым. Әлеге кибет ышанычлылардан дип саныйм, күп кенә агач-куакларым да шуннан алынган, сыналган.

:: Розаларны корткыч бөҗәкләр дә үз итә дип беләм, алардан ничек котылырга?

– Быел розаларны гомер күрмәгән корткычлар басты. Бөре талпаны, долгоносик, теләә зыян салды. Моңа кадәр болай булганы юк иде. Ике тапкыр агу сиптердем инде. Беренче тапкыр «Фитоверм Форте» сиптем, ул көчсезрәк булды, ахры. Икенчесендә «Биотлин» белән эшкәрттем.

Тәмле булсын!

БАКЧА ҖИЛӘГЕННӘН РЕЦЕПТЛАР

КАЙНАТМА

Кирәк: *1 кг җиләк, 1 кг шикәр комы, 2 г лимон кислотасы.*

Бакча җиләге кайнатмасын үзен генә дә, банан, ананас, лимонише җиләк-җимешләр кушып та ясарга була.

Чистартылган җиләккә 150–200 г шикәр комы салып болгатып, 3 сәгать тотарга. Барлыкка килгән сиропны кәстрүлгә салып утка куярга. Аңа калган шикәр комын өстәп, 5 минут эреп беткәнче кайнатырга. Әзер сиропка җиләкләрне салып, кайнатып чыгарырга. Кайнап чыккач, сүрән утта тагын 2 минут кайнатып алырга. Аннары сүндереп, кәстрүл капкачын каплап, 2–3 сәгатькә калдырырга. Суынган кайнатманы сүрән утта 5 минут кайнатып алырга, моны шул рәвешле 3 тапкыр кабатларга була. Лимон кислотасын өстәгәч, 10 минут кайнатып алырга һәм стерильләштерелгән банкаларга кайнар килеш тутырып, каплап куярга кирәк.

ДЖЕМ

Кирәк: *1 кг бакча җиләге, 700 г шикәр комы, 5 г лимон кислотасы.*

Куерак булсын өчен желатин яки пектин өстәргә мөмкин.

Чистартылган җиләкне кәстрүлгә салып кайнатып чыгарырга. Кайнап чыккач, сүрән утта 10 минут кайнатып алырга. Аннары аңа шикәр белән лимон кислотасын салып, эреп беткәнче болгатырга. Стериль банкаларга салып, калай капкач белән капларга да төреп торарга. Суынгач салкын урынга куярга.

КАК

Кирәк: *600 г җиләк, 2 аш кашыгы лимон согы, 6 аш кашыгы бал.*

Чистартылган җиләккә бал, лимон согын кушып яхшылап блендерда изәргә. Әзер җиләк боламыгын табага пергамент кәгазе җәеп, өстенә юка гына итеп салырга. 75 градуска кадәр җылытылган мичтә 3 яки 3 сәгать ярым чамасы тотарга. Әзер булганнан соң, какны бүлгәләп, төреп куярга мөмкин.

ТУҢДЫРУ

Бакча җиләген туңдырганда аның файдалы үзлекләре озаграк саклана. Еш кына җиләкләрне, артык су җыелмасын өчен, юмыйча туңдыралар. Пычрак булса, тиз генә суда чайкап алып, сөлгегә җәеп киптерегез. Җиләкләрне бер кат итеп тәлинкәгә тезеп, суыткычта катырганнан соң, контейнерларга тутырып куйсагыз, алар яңа өзгән кебек сакланачак.

Бакчачы киңәше

ВАКЫТЫНДА САКЛАНУ КИРӘК

Бакчачы-блогер Рәмзия ӘХМӘДУЛЛИНА киңәше

– Яшелчәләр өчен куркыныч булган ончыл чык авыруын вакытында күреп, чарасын күрү кирәк. Бу – күгәрек авыруы. Артык дымлы, салкынча һава торышы булганда килеп чыга.

Бу очракта «Алерин-Б» препараты кулланабыз. Инструкциясендә язылганча, кояшсыз вакытта, иртүк яки кич эшкәртәбез. Гадәттә, авыру бик азмаган булса, бер тапкыр эшкәртү дә җитә.

Белеп тор!

ЯРАН НИГӘ СУЛА?

Яфраклары саргая. Яранның яфраклары сыгылмалы, ә кырыйлары саргайган икән, димәк, аңа дым җитми. Әгәр яфраклары шәлперәйгән һәм чери башлаган икән, кирәгеннән артык су сибелгән. Ике очракта да яфраклары коелырга мөмкин.

Яфрак читләре кызара. Димәк, температура кирәгеннән артык түбән. Салкын урыннан җылырак урынга күчереп карагыз.

Сабагы карала. Сәбәбе – бактерияләр һәм гөмбәчекләр китереп чыгарган кара аяк чирендә. Мондый авыру гөлне ташлавыгыз хәерле. Киләчәктә стерильләштерелгән туфрак кулланырга һәм гөлгә артык су сипмәскә тырышыгыз.

Шәрә сабак. Яранның аскы яфраклары коелу яктылык җитмәүне аңлата. Ул – яктылык яратучы, кояшка чыдам гөл.

ИХЛАС КЕШЕНЕ ҖӘННӘТ КӨТӘ

Адәм баласының һәркайсы җәннәтле булырга, аңа ирешергә тели. Аллаһы Тәгалә исә Үзе риза булган колларына гына оҗмах ишекләрен ачачак. Коръәннең «Вакыйга» сүрәсендә: «Бер сыйныф – уң тараф кешеләредер, уң тараф кешеләренең җәннәтләрдә хәлләре ни хуш яхшыдыр, вә икенче сыйныф – сул тараф кешеләредер, сул тараф кешеләренең хәле җәһәннәмдә ни ямандыр», – дигән сүзләр бар.

Җәннәт белән җәһәннәм турында Коръәндә тагын ни диелә? Бу урыннарда кешене ни көтә? Адәм баласы җәннәтле булырга омтылса, нишләргә тиеш? Бу һәм башка сорауларга Алмаз хәзрәт ГАЛИМҖАНОВ ачыклык кертте.

:: Җәннәт һәм җәһәннәм турында Коръәндә ни диелә?

– Коръәни Кәримдә дә, пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) хәдисләрендә дә бу урыннар тасвирлана. Адәм баласы бу дөньяда яшәп киткәннән соң, кыямәт көне узгач, үзенең яшәү рәвешенә, кылган гамәлләренә карап хисап тоткач керәчәк урыннар бу.

Җәннәтне Аллаһы Тәгалә бик матур, тыныч урын итеп тасвирлый. Бирелә кеше теләгән бөтен нәрсә дә булыр, ди. Ягъни кеше бирелә кайгы-хәсрәт күрмәс, ихтыяҗлык кичермәс. Бу урын тәкъва булган, иман китереп, изге гамәлләр кылып яшәгән кешеләр өчен.

Аллаһы Тәгалә җәһәннәмне куркыныч урын итеп тасвирлый. Монда иман китермичә, кешеләр рәнҗетеп, бозыклык кылып, Җир йөзендә тәкәббер булып йөргән кешеләр керер. Анда адәм баласын газаплар көтә, ул бирелә кылган гамәлләре өчен зур җәза ала.

:: Җәннәтле булу өчен адәм баласына нишләргә соң?

– Адәм баласы иман китереп, гыйбадәтләр кылырга тиеш. Моннан тыш ул әдәпле, әхлаклы, эчке дөньясы белән дә матур булырга тиеш. Шундый хәдис бар: «Пәйгамбәребез (с.г.в.) янына килеп: «Йә, Рәсүлебез! Минә бер хатын бар. Ул фарыз намазларын үти, уразасын тота, өстәмә сөннәт гамәлләрне үти, нәфел намазларын да укый, садака да бирә. Әмма теле бик әшәке. Күршесен гел рәнҗетә», – диләр. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Бу хатынның урыны – җәһәннәмдәдер», – ди. «Йә Рәсүлебез! Менә бер хатын бар. Аның фарыз гамәлләрне генә үтәрлек мөмкинлеге бар. Кәҗәсе бар. Ул шуның сөте белән күршесен гел сыйлый», – диләр. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Аның урыны – җәннәттәдер», – ди». Ягъни намаз укуыбыз, ураза тотуыбыз гына берни түгел әле ул. Дин кушкан хөкемнәрне генә үтәп, эчке дөньясы матур булмаса, андыйлар җәннәткә кермәскә дә мөмкин, дип кисәтә Аллаһы Тәгалә.

:: Җәннәттә кешене ни көтә?

– Тынычлык көтә анда. Ул бүген безгә бик тә җитми. Җәннәттә бар нәрсә дә камил, бар нәрсә дә җитеш. Ул анда ял итәчәк, рәхәттә булачак. Җәннәттә җил дә салкын, кояш та эссе булмас, агач астыннан елгалар агар. Җәннәттә – яктылык, нур, рәхәтлек кенә. Иң мөһиме – анда нурлы, күңеле мәхәббәт белән тулы Рәсүлебез – Мөхәммәд (с.г.в.).

:: Ә җәһәннәмдә?

– «Анда каты уттыр, бу дөньядагы ут – аның 70 мәртәбә җиңеләйтелгән төредер», – дип кисәтелә Коръәндә. Җәһәннәмгә иман китермәгәннәр эләгә. Кешенең анда эчәсе бик нык килер, әмма, эчәр суы булмау сәбәпле, ул кеше тәненнән чыккан суны эчәргә мәҗбүр булыр. Ашыйсы ризыгы да кактус сыман чәнечкеле, ачы ризык булыр. Кешенең тәне янар, әмма аның урынына яңа тире чыгар һәм бу газап бертуктаусыз кабатланыр. Җәһәннәмнең иң куркыныч газабы монафыйкларга, ягъни икейөзлеләргә эләгер. Мәсәлән, динле дә, әмма бозык кеше.

:: Җәннәттә хур кызлары да бар, диләр. Алар кемгә эләгер?

– Хур кызлары олы дәрәҗәләргә ирешкән кешеләргә эләгер. Әйтик, гаиләсенә яхшы мөнәсәбәттә булганнар, дин юлында гел яхшы гамәлләр кылганнар өчен, Ватанын, динен яклап, яу кырында ятып калганнар өчен.

:: Кемнәр җәннәткә туп-туры, берниндн каршылыксыз эләгә?

– Җәннәткә Аллаһы Тәгалә белән ихлас булганнар эләгә. Шәһит киткәннәр җәннәтле булыр. Ягъни үз тормышларын нәрсә өчендер корбан итүчеләр. Әйтик, бала тудырган вакытта вафат булган хатын-кызлар. Эч авырулары белән, иман китергән мәлдә үлеп киткәннәр дә җәннәтле булыр. Җимерекләр астында калучылар да, балигъ булганчы үлгән сабыйлар да җәннәткә турыдан-туры керер. Суда батып үлүчеләр, яу кырында калганнар – һәммәсе дә җәннәткә ирешер. Кешеләргә ярдәм итеп, игелекләр эшләгәндә ахирәткә күчкәннәр дә Аллаһы Тәгалә рәхмәте белән җәннәткә керер. Шуларга да хур кызлары эләгер. Иман дәрәҗәсе нык булган кешене дә җәннәт көтә.

ru.freepik.com

Хикмәтле сүз

- *«Кайда гына булсагыз да, сезгә барыбер үлем ирешер, хәтта күккә тәрәлгән бина эчендә булсагыз да».*
70 яшьлек Илфат абый заманадан калышмаска тырыша. Интернет серләренә төшенеп килә. Хәзер менә социаль челтәрдән аралашырга өйрәнә. «Үзем генә ерып чыга торган түгел. Яшьләр аны су урынына эчә. Сабакташларым булыша. Тырышканны күрәләр, укытучылар да начар билге куймый. Хатыным да хуплап тора. Шулай булмаса, шушы яшьтә мондый адымга барыр идеммени?» – ди ул.

Заманында Алабуга мәдәни-агарту училищесын тәмамлаган ул. Соңгы вакытта Арча һәм Биектау районында балаларны биергә өйрәткән. Быел Теләче укучыларын баянга өйрәтергә нияте бар. «Музыкаль әсәрләр өйрәнә башладым. Мин бит өч бармак белән генә уйный торган баянчы түгел, дипломым бар», – ди Илфат абый.

Тагын бер шөгыле бар әле аның. Инде 50 елдан артык колгага менү белән мавыга ул. Үзе белән гармунын да алып менә әле. Ә менеп җиткәч, уйнап җибәрә.

– Казанның Дәрвишләр бистәсендә соңгы ике ел рәттән беренче урын алган идем. Әмма бүләген бирмәделәр. Аягыма сагыз сөрткән идем. Быел барыбер осталыгымны күрсәтәчәкмен. Миңа юкка гына «маймыл» кушаматы такмадылар бит, – ди Илфат абый.

Үзе яшерми: 70 яшьтә егет булып йөрү җиңел түгел. Шуңа күрә ул, күнегүләр ясап, чаңгы шуып, үзен тәртиптә тотарга тырыша. Иҗатны, тормышны ярату исә яхшы кәеф өсти. Сокланырлык бит!

Сәрия МИФТАХОВА әзерләде

БЕЗНЕҢ ЗАМАН БЛОГЕРЫ

Иң якын дус, сердәш, иптәш, кайда нәрсә арзан икәнен төгәл белүче, ашка күпме тоз саласын әйтүче, фәлсәфә коручы, синең белән бергә елаучы да, көлүче дә, ир һәм хатын, әниләр һәм бәбиләр мөнәсәбәтләрендәге киңәшче дә... Вазыйфалар мең – блогер бер. Аның җилкәсенә, ай-һай, күп нәрсә төшкән. Ул – кем өчендер туганнан да якынрак кеше. Безнең заман блогеры – кем ул? Халык кемнәргә иярә? Блогерларны карап, шул хакта уйландык әле.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Телефон тотсаң кулга...

Россиянең кайбер «интернет йолдызлары»на суд эшләре ачыла башлагач, җәмәгатьчелек кабаттан блог алып бару өлкәсен көйләү мәсьәләсенә игътибар итте. Кем блогер, ә кем түгел? Алар өчен аерым закон кирәкме? Ни әйткәннәрен, ни күрсәткәннәрен контрольдә тотасымы? Акча эшлиләр икән, салым түләтәсеме? Кем әйтмешли, сораулар күп, җаваплар гына ишетелми.

Ярар, Россия күләмендә танылган «блогер-йолдыз»ларга үрелгәнче, үзебезнекеләр янына төшик әле. Бит бездә «барысы да ал да гөл» дип куясың интернетны ачкач. Бакчада эшләү, ашарга пешерү, әти-әниләр янына авылга кайту, «Iphone» сата торган кибеткә реклама ясау, бизәнү, кием-салым кибетләренә, кафе-рестораннарга ташлама белән уртаклашу, өйдәге көндәлек мәшәкатьләрне оста итеп башкарып чыга алуны күрсәтү, нинди киемнең нинди чара өчен яхшырак икәнен аңлату – күпчелекнең, блогерлар теле белән әйтсәк, «контент»ы шундый. Аерып әйтерлек, «менә бу чын блогер!» диярлекләре аз. Чөнки кулында камералы телефоны булган һәр кеше – блогер. Кыскасы, бездәге блог өлкәсе – винегрет хәлендә. Анда барысы да бар, буталган һәм шул ук вакытта бернәрсә дә юк кебек. Әмма хөкем чыгаручылардан булмыйк. «Кызларда да була гаеп», – дип җырлыйлармы әле?

Кытлык юк

Татар аудиториясе нинди блогерларны үз итә? Этноблогинг, аналитика белән мавыккан блогерлар ни өчен аз? Ни өчен бакча белән аш-судан ерак китә алмыйбыз? Беренче татар блогеры саналган Ринат Галиәхмәтовка шул сорауларны бирдек.

– Аудиторияне татармы, урысмы дип аерып булмый. Блогинг өлкәсендә шундый шәп сүз бар: һәр блогерның – үз аудиториясе. Күпме кеше булса, шулкадәр фикер дә. Шуңа да безнекеләр татарларны да, башкаларны да яратып карый дияр идем, – ди блогер. – Мөнәсәбәтләр, эстрада, гаилә темаларын үз итәләр. «Лайфстайл» блогерларны яраталар инде. Алар тормышын матур итеп күрсәтә беләр. Бигрәк тә кыз-блогерлар. Сөйләшү, серләшү, киңәшләшү бар аларда.

Ринат әйтүенчә, һәр кешене дә блогер дип санап булмый. «Бу кешенең кешеләре күп, аудиториясе зур булса да, аның танылган булу-булмавы да роль уйный бит әле. Ягъни «медийная личность» дибез. Социаль челтәрләрдә күпләр гив, марафоннарда катнашып үсте. Блогерлар кирәкле, файдалы контент төшерергә тиеш инде ул. Һәр телефон тоткан, һәр нәрсәне төшерүче бу исемне йөртә алмыйдыр. Әмма үзләрен шулай хис итсәләр, афәрин, үсәргә, кызыклы эчтәлектәге контент ясарга тырышырга кирәк», – ди ул.

Татар телендә җитди блогерларга кытлык бармы дигән сорауга, ул:

– Блогер булып сәхифә алып бара торган кеше нәтиҗә көтә. Язылучылар, фикер көтә. Аналитик язма яздың, ди, әмма халыктан кайтаваз юк. Бушлыкка язу буламы бу? Киң аудитория булмагач, блогерның да кәефе төшә. Моны кирәксез дип саный. Шуңа күрә мондый темаларга алынмыйлар, – дип җаваплады. – Мин авыл тормышын унар минутлык видеолар аша күрсәтә идем. Хәзер замана үзгәрде. Озын видеолар карыйсы килми. Заманага карап, үзгәрергә кирәк, дисең һәм үзгәрәсең.

САН

2022 ел мәгълүматларына ышансаң, илдә:

➤2–5 мең язылучысы булган 755 мең блогер;
➤5–10 мең язылучысы булган 300 мең блогер;
➤10–100 мең язылучысы булган 255 мең блогер;
➤100 меңнән 1 миллионга кадәр язылучысы булган 18,5 мең блогер;
➤миллионнан артык язылучысы булган 1 меңнән артык блогер бар.

Ринат халыкның – аудиториянең кызыклы бер үзенчәлегенә дә тукталды.

– Яхшы яңалыкны кеше урап уза. Ә менә болар талашкан, болар аерылышкан дигән сүз чыкса... Гайбәт сатучы блогерларны бик яраталар. Алар инде гайбәт сатам дип уйламыйдыр да... «Большая стирка» тапшыруы кебек! Кеше менә шуңа иярә, үзара «болай булган, фәлән иткән» дип бүлешә, – ди блогер. – Мин негативта катнашмыйм. Гади, позитив контент яклы. Язылучыларым да шундый.

– Блогерларга иярү дигәннән, хәзер блогерларга кытлык юк дип саныйм. Ике кешенең берсе – блогер. Аларның күбесе – декретта үз юлын бизнеста тапкан хатын-кызлар. Чыннан да, күп ич алар! Үземнең танышлар арасында гына да гомер уйламаган кешеләр блог алып бара. Гадәттә аларның блогында – авыл тормышы, аш-су рецепты, көнкүреш күрсәтелә. Челтәрле бизнес белән шөгыльләнүчеләр дә блогер булып бетте, – ди Рәфидә Галимҗанова. Журналист буларак, үзе дә хис-кичерешләрен сәхифәсендә урнаштырырга ярата ул. Үзе алай санамаса да, «блогер» дигән аты бар әңгәмәдәшебезнең. – Шәхсән мин аш-су осталарын, бизнесвуменнарны карамыйм диярлек. Бер файда тапмыйм. Күп кенә татар блогерлары сәхифәләрен рус телендә алып бара хәзер. Аларны да карамыйм.

Ксения Романова – этноблогер. Ул – чуаш милләтеннән, блогын да ана телендә, халкына хас үзенчәлекләрне кертеп алып бара. Килешергә кирәк: аның кебек сәхифә алып баручылар күп түгел.

– Блогер-юмористлар күбрәк, чөнки аудитория аларны карарга ярата. Үзем урнаштырган язмалар белән көлдерә торганнарны караучылар санын чагыштырганда да сизелә ул. Юмор белән аудиторияне җыю җиңелрәк, димәк, – ди ул. – Этноблогинг бөтен кеше өчен дә кызыклы түгел. Син бер милләт турында сөйлисең, сәхифәне шул милләт кенә аңлаган телдә алып барасың, аудитория дә шул халык белән генә чикләнә. Караучылар санын җыярга була ул, сыйфатлы контент кирәк.

Соңгы сүз урынына

Язма әзерләгәндә, блогерларның аудиториясен тәшкил иткән халыкның фикерләрен дә сораштык. Кемнәрне карыйлар икән алар? Күпчелек телгә алган блогерлар исемлеге чагыша. Исемнәрен атап тормыйк, үзләре телендә сөйләшсәк, алар бу юлларны язучыга реклама өчен түләмәде бит. Блогерларга карата булган берничә фикерне генә язабыз да нәтиҗә ясауны укучы хөкемә калдырабыз. Без әйтмәдек, яме!

«Бер үк нәрсәне төрлечәгә әйләндереп, тузга язмаган нәрсәләр күрсәтеп, җиңел юл белән акча эшләүчеләр. Күзгә чалынса, шаклар катып карап алам да тизрәк ябып куям».

«Блогерлар – кешенең кадерле вакытын сарыф итеп, халыкның болай да юк аңын алып, акча эшләүчеләр. Тузга язмаган, мәгънәсез пост куючылар, барыбыздан да оста пешекчеләр, тормышларының астын-өстен дөньяга чәчүчеләр...»

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ФИКЕР

Юлия ОСМАЧКИНА, клиник психолог:

– Әгәр дә һәр кеше «менә минем нәрсә белән шөгыльләнүемне карагыз», «минем ничек яшәгәнне күзәтегез» дип сөйләп торса, кешеләр, ахыр чиктә, чынбарлык белән элемтәне югалтачак. Камил, матур тормыш белән мәҗбүриләп тагылган фикерләр күп булачак. Күпчелек блогерлар үзләрен һәм тормышларын шулай күрсәтә бит. Алар карaучыларына үзләре теләгәнне генә күрсәтә. Ә алар кешеләрнең үзләрен бар яктан камил итеп күрүләрен тели. Блогерлык белән мавыгу мәгълүмат күплегенә һәм виртуаль дөньяга бәйлелеккә китерергә мөмкин. Мәсәлән, блогер киңәш иткән шампунь куллану, ул әйткәнчә яшәү. Блогерлар өчен дә массакүләм блогерлык куркыныч, чөнки «иң яхшы», «иң кызыклы» статусына лаек булу өчен көчле көндәшлек башланачак. Алар: «Тагын нәрсә уйлап чыгарырга икән?» – дип, кызып китәчәк.

ГӨЛФИЯ МӘГЪСҮМОВА:

«СЫНАУЛАР ТИКМӘГӘ БИРЕЛМИ»

Арча районының Ташкичү авылында яшәүче Гөлфия апага сокланмыйча мөмкин түгел. Үз куллары белән йорт салган, тирә-як авылларда яшәүчеләргә мич чыгарып, машина алган кеше ул. Тормышта шактый авырлыклар белән очрашса да, булганына сөенеп, тормышына шөкер итеп яши.

– Ашытбаш авылыныкы мин. 20 яшемдә бу авылга кияүгә килдем. Әле мин кияүгә дә чыгасы түгел идем. Ул чакта Казанга китеп урнашкан вакыт. 16 нчы заводта эшлим. Хезмәттәшләрем шулкадәр әйбәт кызлар иде. Тик әти-әни сүзенә каршы килә алмадым. Алар әйткән закон иде бит ул чакта. «Кияүгә чык», – диделәр, чыктым, – дип искә ала Гөлфия апа. – Мин килгәндә каенатам исән түгел иде. Каенанам каенсеңлесе белән яши иде. Кадер-хөрмәттә яшәделәр. Әни дә, апа да риза булып киткәндер дип уйлыйм.

Гөлфия апа килен булып төшкән йорт иске була. 11 балалы гаиләдә үскән, гел әтисе янында кул арасына кергән Гөлфия бер эштән дә курыкмый.

– Урман янында яшибез бит. Шуннан тактага ярарлык агачлар әзерләдек. Шуның белән иң элек капка-койманы яңартып куйдык. Аннары мунча салдык. Ирем белән икәү бергә эшләдек. Шуннан соң өйне яңартасы килде. Өй салдык. Төзелеш башлагач, гел ярдәм килеп торды. Яхшы күңелле кешеләр булыша иде, – дип сөйли Гөлфия апа. – Минем ирем бик юмарт, кешелекле булды. Күңеле бик яхшы иде. Тик гомере генә кыска булды. Матур гына яшәгәндә, кинәт үлеп китте. 41 яшемдә тол калдым. Кечкенә улымны өйләндерәбез, дип, кыз сорап кайткан чак. Никах көннәре дә билгеле иде. Туй итәргә 23 көн кала, әтисен мәңгелеккә югалттык. Ул чакларда бик авыр булды. Ярый, якыннарым, дусларым, күршеләрем җылы сүзне кызганмады.

Хәзер инде улының өч баласы бар икән. Олысы да өйләнгән. Алар хатыны белән ике бала үстерәләр.

– Олы улым, өйләнәм, дип кайткач, энесе белән икесе төп йортта кем каласын хәл иттеләр. Абыйсы төп йортта калырга булды. Кечесенә йорт кирәк бит инде хәзер. Башта бик озак уйлаштык. Әзерне сатып алсаң да, ипотекага алсаң да, түләргә кирәк. Аннары инде үзебездән ерак түгел бер пуҗымны сатып алып, кода-кодагыйлар белән киңәшеп, шунда өй җиткерә башладык. Төп йортта ниләр бар, кече улымның өендә дә шулар булганчы бергә ярдәмләштек. Бар әйбер уртак булды. Хәзер дә шулай. Улларым туганлык җепләрен ныгытып яшәргә тиеш дип саныйм, – ди Гөлфия апа.

Улы йорт җиткергәндә дә ярдәме тия Гөлфия апаның. Ирләр эшен белгәч, ике улын да хезмәт белән тәрбияли ул. Кирпеч тә өя беләләр. Белми ни! Әниләре тирә-якка дан тоткан мич чыгаручы булсын да, өйми кара! Заманында Гөлфия апаның бушаганын көтеп кенә торалар. Бер йортта мич чыгарып бетергәнен икенчеләр көтеп тора.

– Үзебезгә мич кирәк иде. Ашытбашта бер оста бар. Моның янына бер бардым, ике бардым. Йә алып китеп баралар, йә эштән бушамый. 10 көн көттек. Берәүләргә кереп моның мичен карап чыктым да үзебезгә сала башладым. Бер атна маташтым. Шуннан икенче көнне үк мине Ашытбаштан бер кеше үзләренә алып китте. Аларга өч көндә чыгардым. Әкренләп кул шомарды. Бер көнгә бер мич чыгара башладым. Берсе өчен 500 сум акча бирәләр иде. Үз гомеремдә йөзләп мич ясаганмындыр, – ди Гөлфия апа. – Шул акчаларыма машина сатып алдым. Иске иде ул. Әмма өйрәнергә ярап торды. Элек бит машина йөртү таныклыгын хәзерге төсле үк тикшереп бирмиләр иде. Кабызып, туктамыйча бер йөреп килә алсаң, таныклык синеке. Хәзер инде җиденче машинамда йөрим. Машинасыз беркая да барып булмый хәзер. Ярый укыганмын, дим.

Берзаман Гөлфия апа авырып китә. Сәбәбен белмиләр. Бармаган җире калмый. Бер өшкерүче әби булыша. Шуннан соң ул намаз укый башлый. Дингә килү хәлен яхшырта.

– Ул чактагы үз хәлемне үзем генә беләм. Җанымны кая куярга белмәгән вакытлар бар иде. Коръән сүрәләре укып кына уңайландым. Әкренләп үземдә ниндидер сәләт барлыгын сизеп алдым. Төшләремдә кешеләрне өшкерергә кушалар иде. Белгән догалар белән авыруларга ярдәм итә башладым. Шөкер, догамның шифасы тия. Тик бутамасыннар, мин күрәзәче түгел. Берәүгә дә берни әйтмим. Аллаһы Тәгаләдән шифа сорап, кешеләрне дәваларга тырышам, – ди Гөлфия апа. – Миңа кеше табиблардан шифа тапмагач килә. Доганың көче зур аның.

Гөлфия апа бар яктан килгән. Динле дә, авыл тормышында да актив катнаша. Мәдәният йортын җитәкли. Кайчандыр Гүзәлия исемле авылдашы белән бергәләп оештырган «Өммегөлсем» ансамбльләре гөрләп эшләп тора. Ансамбльнең хәзерге җитәкчесе Тәнзилә Вәлиева бер эшкә дә иренми икән. Авылдашларын төрле бәйгеләргә йөртеп кенә тора. Узган ел авылларында «Сөлгеле капка» дигән бәйрәм уздырганнар. Анда республиканың төрле районнарыннан һәм күрше төбәкләрдән 45 фольклор коллективы килгән. Быел бу бәйрәмне тагын уздырмакчылар.

– Тормыш дәвам итә. Мин хәзер авырлыкларның, сынауларның тикмәгә генә бирелмәвен аңладым. Дин кушканча яши башлагач, юлларым ачылды. Ә бит моңа кадәр гел каршылык иде. Дөрес итеп яши белмәү аркасында тилмердем, – ди ул. – Хәзер инде сөенеп яшим. Ике улым, ике киленем, оныкларыма кирәк мин. Киленнәрем дә кызларым кебек булды. Алар тигезлек белән яшәсен. Ялгызлык рәхәт нәрсә түгел. Тагын шуны әйтәсем килә – дөрес юлдан атлап яшәргә тырышыгыз! Гомер сизелми дә үтә. Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәсәк иде.

МОНДЫЙ ХӘСРӘТ КҮРГӘН ЮК ИДЕ...

Бөтен авыл елый. Дүрт бала әнисез калган. Юл фаҗигасенә эләгеп гомере өзелгән 46 яшьлек Ләйсәннең якыннарын юатыр сүзләр табып булмый. Бу хәсрәт Ләйсәннең әнисен дә нык какшаткан. Туганнары исә, бердәм булып, сабыйларны ничек тә ятим итмәскә тырышачакбыз, диләр.

Шушы көннәрдә Әгерҗедә узган мари бәйрәме Семыктан өйләренә – Уразай авылына кайтканда өч хатын-кыз һәм ике бала утырган машина юл фаҗигасенә эләгә. Машинаны йөртүче Ләйсән Гарифуллина шунда ук вафат була. Янәшәсендә утырып барган игезәк улларының берсенең хәле бик авыр. Артта утырган ике ханымның да аяк-куллары сынып беткән. Ә менә игезәк малайларның икенчесенә, шөкер, берни булмаган.

– Ләйсән яшь булса да, күпне күрде инде ул. Кияүгә чыгып, матур гына яши башлаган иде. Бер кыз, бер уллары туды. Тик, кызганыч, киявебезнең башында яман чир таптылар. Ул кыска гомерле булды. Соңрак сеңлем икенче тапкыр кияүгә чыкты. Айдар белән аларның ике игезәк уллары туды. Тик бу киявебез дә кыска гомерле булды. Балаларга өч яшь чагында юл фаҗигасендә һәлак булды, – ди абыйсы Дамир Мулләхмәтов. – Хәзер менә үзе дә юк. Ул көнне бәйрәм булгач, ул ике малае белән шунда киткән. Янәсе, күңел ачып кайталар. Кайтыр юлда машиналарына тагын ике хатын-кыз да утырган.

Фаҗиганең нечкәлекләрен белмим, тик шунысы билгеле: сеңлем юл кырыена очкан.

Ләйсәннең олы кызы кияүдә, өченче бәбиен көтә икән. Улы армия сафларыннан кайтып, әнисе белән бергә яшәгән. Ул әле өйләнмәгән. Альмир белән Альфирга – 12шәр яшь.

– Ул балаларны мин баянга өйрәтә башлаган идем. Альмирыбыз, бер җирем дә авыртмый, дисә дә, хастаханәгә алып барып күрсәтергә җыенабыз. Сабый шок хәлендәдер, дибез. Альфирның гомере өчен табиблар көрәшә. Сабыйның талагы өзелгән. Ул реанимациядә. Исән-сау савыга күрсен инде, – ди Дамир абый.

Әтисез үскән дүрт сабый инде бердәнбер юанычлары, терәкләре – әниләрен югалтты. Ничә яшьтә булсаң да, әни кирәк! Дүртесе дә кызганыч. Буй җиткән балалары үз тормышын күтәрләр дә, кечкенәләр нишләр?

– Аларның әтиләренең сеңлесе бар. Гел аралашып яшәделәр. Альмир да, Фәридә апаларда яшибез, дигән. Алар сабыйларны алырга каршы түгел. Без дә ташларга җыенмыйбыз. Бу авырлыкны бергә-бергә ничек тә күтәрербез дип уйлыйм, – ди Дамир абый. – Ләйсәннең бик тә рульгә утырасы килде. Берничә ел элек «права»га укыды. Шул машина алып китте дә инде үзен...

Авылдашлары Ләйсәннең гаиләсенә ярдәм итү максатыннан акча җыя башлаган. Бу акча игезәк малайларга тотылачак. Булышырга теләүчеләр өчен Дамир Хаҗиәхмәт улы Мулләхмәтов исемендәге Саклык (СБЕР) банк картасы **89172638867** номерына беркетелгән.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

АЙГӨЛ ӘХМӘТГАЛИЕВА:

«МИНЕМ ТУРЫНДА КИТАП ЯЗЫЛМАС...»

Укучы китап укымый дигән заманда язучы нинди уй-фикер белән яши? Аннан хәзерге заман турындагы әсәрне таләп итү дөресме? Ни өчен фантастик әсәр язылмый? Болар һәм башка мәсьәләләр турында язучы Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА белән сөйләштек.

:: Иң популяр җырчылар да зал тутыра алмый азапланганда, халыкны китап укытып буламы?

– Була. Моның өчен иң беренче чиратта, бездә халык китап укымый, укырлык китап юк, дигән ялган фикерне әледән-әле кабатлап, кешенең баш миенә сеңдерүдән арынырга кирәк. Мин моңа бик күп җирдә очрашуларга баргач, инандым. Менә шунда урта һәм өлкән буынның китапка мөнәсәбәтен күреп шаккаттым. Юкса үзем дә хәзер укымыйлар дип алдана башлаган идем инде. Яңа китап булса, әсәр халыкның үз ярасын, үз җанын чагылдырса, аны сагынып, сусап көтеп алалар. Сорыйлар, фикер алышалар. Авырткан җир – мондый очрашуларда яшьләр бармак белән генә санарлык. Бу җәһәттән китапханәчеләрнең хезмәте тиешенчә бәяләнәме икән дигән сорау туа миндә. Ярый инде, без, язучылар, коры рәхмәт белән булса да беркадәр бәялибез фанатизм белән эшәүче шушы фидакарьләрне. Ләкин мин дәүләткүләм, югарырак дәрәҗәдә исәпкә алуларын теләр идем.

:: Нинди китапны укыйлар?

– 7–8 ел элек халыкка «Җиңел» әйбер кирәк иде. Бүген укый, икенче көнне оныта ул аны. Сериаллар белән шулай булды, исеңдәме? Үлә-бетә карадылар да берзаман туйдылар. Хәзер китап белән шундый хәл. «Җиңел» китаптан бигрәк, тарихи әсәрләр сорыйлар. Шәхесләр турындагы китаплар белән кызыксыналар. Яшь буын фантастика сорый. Аларның зары урынлы, яшьләр өчен татарча фантастик әсәрләр юк диярлек.

:: Ә ни өчен татар язучысы фантастик әсәр яза алмый? Гуманитар белем белән генә язып булмыймы аны, әллә инде халык хыялланудан да курка башладымы?

– Әгәр миңа, фантастик әсәр яз әле, дисәләр, мөгаен, кистереп, юк, язмыйм, дип җавап бирер идем. Шәхсән үзем, булган булсын инде, яки әкият яратам, яки реалистик әсәрне. Хыяллана белмибез, дип әйтмәс идем. Татар халкы – романтик жанрны да үз күрә, шулай да барыбер реалистик тормыш белән яши торган халык. Ул бүгенге белән дә яшәми кебек. Кичәге көн белән яшибез, һаман да шул элеккеләрне мисал итеп китерәбез, байлыкларыбыз, тарихыбыз белән мактанабыз. Шул ук вакытта алдагы тормышны уйлап ашкынабыз. Иртәгә әйбәтрәк булыр төсле. Фантастик әсәр дигәндә, мин үрнәк итеп Фатих Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт»ен әйтер идем. Гасыр башында язылган әсәр бүгенге тормышыбызны көзгедән күреп язган кебек. Фантастик әсәр язу өчен Аллаһы Тәгалә тарафыннан язучы күңеленә менә шушындый илаһи сернең салынуы кирәктер. Ул сер булмаса, үзең уйлап утырып кына язылмый ул. Әгәр инде кайчан да булса шундый илһам иңсә, ул әсәр туар... Ихтыяҗ бар дип кенә андый әсәр язарга мин әзер түгел. Бәлки башка язучыларда да шундый хикмәттер.

:: Аннары халык кызганырга ярата безнең. Бәетләр иҗат итү дә, мөгаен, шуннан киләдер. Димәк, кызганыч романнар укылышлы булыр иде. Хәния Фәрхи, Сәхипҗамал Волжская турында язганда бу алымны кулланмадыңмы?

– Кызгану микән – чыннан да, кемдер исерек ирен, кемдер баласы проблемаларын онытып, китаптагы шундый геройлар белән яшәп, алар өчен җан ата. Бәлки, бу халыкның менталитетына да бәйледер. Үзеңнең дә игътибар иткәнең бардыр, Сабан туенда, мәсәлән, ат чабышларында да халыкның игътибары иң беренче килгән аттан битәр, иң азактан килгән атта, аның иярендәге малайда була. Сөлгеләр дә күбрәк аңа бирелә, җылы сүзләр дә. Мөгаен, бу – безнең халыкның үзенчәлегедер.

Язганда минем акылга гына буйсына торган гадәтем юк. Халык укысын да еласын әле, дигән уйның да башыма килгәне юк. Язып тәмамлап, укып чыкканда гына бәгырьне чеметеп, сызлатып ала торган урыннар барлыгына игътибар итәсең. Әмма бу махсус эшләнми. Коры акылны гына тыңласаң, әсәр бик ясалма чыгадыр ул.

:: «Туташ» романы чыккач, чын дөресен язып бетермәгән дигән фикерләр дә ишетелгәләде.

– Чын дөресен язу берничек тә мөмкин түгел. Беренчедән, Сәхипҗамал Гыйззәтуллинаның туган елын күрсәткән документ та юк. Аны күпме галим эзләгән, мин дә күпме архивларда утырдым. Әлбәттә, вакыт бик аз иде, безгә бит ике ел гына бирелде, әмма мин кулымнан килгәнчә эзләндем. Менә шуннан башланган, таяныр нокта булмаган җирлектән ничек итеп чынбарлыкны гына чагылдырып була? Казан архивында аның көндәлекләре саклана, анда да актриса өч дәфтәрендә үз кулы белән өч төрле елны туган елы итеп күрсәтә. Шулай да романның 80 проценты тарихи документларга һәм Сәхипҗамал Гыйззәтуллинаны күреп калган, аның белән аралашкан кешеләрнең сөйләгәннәреннән чыгып язылган. Минем фантазия анда, күп булса, 20 проценттыр. Күбесенчә көндәлекләрдәге фактлар файдаланылды. Анда Кәрим Тинчуринны, Гөлсем Болгарскаяны шактый каралтыбрак күрсәткән язмалар да бар. Шуңа ишарәлисеңдер. Әмма бу көндәлекне язганда Сәхипҗамал Гыйззәтуллина бик өлкән яшьтә булган, һәм без аны шизофрения диагнозы куелып, соңгы көннәрен психоневрологик интернатта үткәргәнен беләбез... Көндәлеккә язган аның бу фикере объективмы, субъективмы – без бит моны берничек тә әйтә алмыйбыз. Икенчедән, алар арасында әчке каршылык, көндәшлек булу да мөмкин. Аны көндәлекләрне укыганда да чамалап була. Бәлки, бу шәхесләргә тап төшерү максатыннан язылгандыр дигән шик тә булганга, мин шундый җирләрен кисеп калдырдым. Ләкин аңлы кешегә аңларлык итеп, диалогларда, актрисаның репликаларында мин аны барыбер чагылдырдым. Сизгер укучы хикмәтнең нәрсәдә икәнен шунда ук сизеп ала.

:: Бездә шәхес кадере бармы? Нишләптер шулай сорыйсы килеп китте...

– Бу сорауга Тукайдан да остарак итеп җавап биреп булмыйдыр.

«Бармыни бездә, гомумән,
чын кеше кадрен белү?!
Без аны кайдан белик,
мескин үлеп аңлатмагач?!» –

дигән ул «Хөрмәтле Хөсәен ядкәре» шигырендә. Мин бу юлларны әле беркөн генә Фарсель Зыятдиновның туган көнендә үземнең «ВКонтакте» битенә алып куйдым. 1 июнь Фарсель абыйның туган көне иде. Ул миңа авылдашым буларак та, кеше буларак та бик якын. Шуның мисалында бу сорауга аңлатма биреп була торгандыр. Кеше бик талантлы, кешелекле булырга, әллә ничә кеше гомеренә җитәрлек эшләр эшләп калдырырга мөмкин. Әмма әрсезлек, ялагайлык, яраклаша белү дигән сыйфатлары булмаса, кадеремне белерләр, хезмәтемне күрерләр дип өметләнергә кирәкмидер. Күпме шәхесләрне беләм, китеп барганнар да, исән чагында кадер күрмәгәннәр дә шактый.

:: Айгөл, «мин язучы булам» дигән фикер кайчан туды? Язучыга, шушы сорауны биргәч, күбесе сүзен, язучы булыр өчен биография кирәк, дип искәртүдән башлый.

– Миңа калса, иң беренче чиратта тормыш тәҗрибәсе кирәктер. Ләкин мин балачактан язучы булам дип хыялланган кеше түгел. Баштарак, биюче булам, дип хыялландым, аннары, Мөсәгыйть Хәбибуллинның «Сулар үргә акса да» дигән романын укыганнан соң, милиционер буласым килде. Анысында әни чабудан тартып туктатты. Мөгаен, Аллаһы Тәгалә үзе күңелгә оеткы салгандыр. Мин китап укырга яраттым. Әти белән әни гомер буе байлык урынына китап җыйды. Кеше сервантына хрусталь җыйганда, алар китап күтәреп кайттылар. Мин аларга шуның өчен мең рәхмәтлемен. Берзаман авыл китапханәсендә мин укымаган китап калмады. Әти китапны Пучы, Усы авыллары китапханәләреннән алып кайта башлады. Әни кайвакыт, аңа бу китапны укырга иртәрәк бит әле, дисә, аны тизрәк укырга тырыша идем. Китап укый-укый «алсу» күзлек кигәнгәндер дә инде. Миңа башта язучы нәрсә уйлый – шуны яза һәм ул бөек профессия вәкиле булып тоелган иде. Бу «алсу» күзлек Казанга килеп, «Мәгърифәт» газетасында эшләгәндә, язучылар белән аралаша-аралаша ватылды. Моны язучыны кимсетү дип кабул итмәскә кирәк. Менә дигән әсәр язган язучының чынбарлыкта икенче кеше булуы, сүз белән гамәленең аерылуы тәэсир иткәндер, күрәсең. Ничек булса да, язучы һөнәре – бер миссия. Син – телисеңме, теләмисеңме – үз вакытыңда каләм аласың, күңеләңә фикер иңә һәм син аны башкалар белән бүлешергә кирәклеген тоясың.

:: Беренче китап һәм тәүге хисләрең?

– «Болытта җиләк үсә» дигән коймак калынлыгы гына китап иде ул. Аның дөньяга туууна Рәшит Бәшәргә рәхмәтлемен. Ул минем иҗатымны укып, канатландырып килә иде. Берзаман «Мәйдан» журналына язучылар килгәч, ул Мөдәррис Вәлиевкә: «Балалар өчен бер китаплык хикәяләре бар», – дип әйтеп куйды. Китап дигән әйбер хыялда да юк иде, ә ул шундый тизлек һәм җиңеллек белән «Мәгариф» нәшриятында чыкты да куйды. Көтелмәгән куаныч иде.

:: Беренчесен язу авырракмы, унынчысынмы?

– Беренчесен мин тәүге тапкыр бәби табарга барган хатын-кыз халәте белән чагыштырам. Әле син үзеңне нәрсә көткәнен дә белмисең. Китаплар саны арткан саен җаваплылык хисе дә арта бара. Укучы синнән беренче китабыңнан да яхшырак китап көтә һәм син тагын да яхшырак әсәр тәкъдим итәргә тиешсең. Һич югы алдан чыкканыннан түбәнрәк баскычка төшмәскә дигән максат куясың. Менә шушы нәрсәләр авырайта, җаваплылыкны көчәйтә.

:: Хатын-кыз язучылар популяррак, диләр, сәбәбен нидә күрәсең?

– Язучылар берлеге эшчәнлегенә карасаң, чынбарлыкта да шулайдыр дигән фикергә киләсең. Чыннан да, интернет сәхифәләргә керсәң дә, иҗат итүчеләрнең күбесе хатын-кыз бит. Аның сәбәпләре күптер инде. Мин инде аның беренчесе ир-атның матди якны кайгыртып, кәгазь-каләм белән булашмавында күрәм. Ир-ат күбрәк тормыш алып бару, акча эшләү юлында. Хатын-кыз эмоциональ, ул элек тә гомер бакый җыру әйткән, бәет чыгарган, каләмгә алыну үзеннән соңгы буынга җылылык калдырырга теләүдәндер ул.

> XXI гасыр башыннан акчага табыну, матди якны өстен куеп беренче планга чыкты. Бер машина бар өйдә, ул җитми, әйбәтрәк кирәк. Кредитка батса бата, ул аны ала. 2–3 ел торган диван ошамый башлый, яңа кирәк. Бу нәрсәләр рухи якны имгәтә. Мин шундый егетне беләм: күңеле тулы моң, шигърият. Язып карады ул. Карады да аннары күзләре зур итеп ачылды. Язып кына дөньяны алып барып булмавына төшенде. Шулай итеп башка юнәлешкә кереп китте.

:: Хәзерге заман әдәбиятында төп өч проблема.

– Аның беренчесе – без бүгенге чорны чагылдырмыйбыз. Җаваплылыктан куркумы, әллә сәяси яктан күп кыйналган татар халкының өркәклегеме – әйтә алмыйм. Гәрчә андый әсәр язылса да, аны кайсы матбугат батырчылык итеп чыгара алыр икән? Икенче проблема – тел мәсьәләсе. Ул артык гадиләшеп, артык җиргә төште кебек. Күп әсәрләрдә моң юк, теле коры, бик үртәләм инде моңа. Нәрсәдән килә ул? Халыкка аңлаешлы булсын дип шулкадәр примитив телгә төшү генә түгел бит инде бу. Өченчедән – геройларыбызны, татар халкының шәхесләрен күрсәтмибез. Бик аз күләмдә языла андый әсәрләр. Әйтик, Сара Садыйкова турында аһ итәрлек нинди әсәр бар? Әле бу телгә килгән иң беренче исем генә.

:: Үзең турында роман язылса, ул ничек аталыр иде?

– Минем турында китап чыкмас, чөнки без – Актаныш ягыннан. Күпләр: «Сездән сүз алып булмый», – диләр... Мин менә сынаулар турында да, гаилә хәлләре, әти-әни хакында да бөртекләп, тәфсилләп бер журналистка да сөйләмәс идем. Бу укучыны һич кенә дә куркытмасын, ниндидер куркыныч әйберләр юк. «Бәхет тыйнаклыкны ярата», – дип әйтәләр бит әле, ул буш сүз түгел, бары шул гына. Аллага шөкер, әти-әнием исән, гаиләм бөтен. Менә шушы бөтенлекне кеше күзеннән сакларга телим. Ялгыш авыздан берәр сүз зарлы чыгып, Аллаһы Тәгалә: «Сиңа бу ошамыймы әле, тагын да авыррак сынау биреп карыйм», – дияр төсле... Шундыйрак уйлар бар. Шәхси тормыш белән мактанасым да, зарланасым да килми.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

РКАИЛ ЗӘЙДУЛЛА

КАРТЫЙ

(ХИКӘЯ)

И китәсе килмәгән иде Амалиянең бу авылга! Гомумән, бер авылга да китәсе килмәде аның. Тик алар гаиләсендә – диктатура. Авторитар режим. «Кайтасың!» – диде әтисе. Каршы килеп маташу файдасыз иде. Амалия инде белә: ирене кысылып, күзе шарланса, әтисе барыбер үз дигәнен итәчәк. «Киребеткән!» – дип, хәтта әнисе дә кулын селти аңа. Юкса кирелектә үзе дә әтисеннән ким түгел. Амалия кайчакта уйлап та куя: өлкәннәрнең һәммәсе дә шундый бит! Үз сүзләре генә сүз.

Кичә генә мәктәптә кыңгырау чылтырады, бүген менә ул авыр сулап авылга китеп бара. Кайтабыз, ди әтисе. Ул кайта, әлбәттә, ул бит кайчандыр шунда туган. Амалиянең исә ул авылны үз гомерендә күргәне булмады. Дус кызлары белән бергә җәйгә дип нинди планнар корганнар иде югыйсә. Иң башта чиркәү янындагы җәйге мәктәпкә барасылар иде. Рухани атакай аларга инде мәктәп кирәк-яраклары да алып куйды, «Килгәч, спорт киемнәре дә бүләк итәрбез, нәфис гимнастика белән шөгыльләнерсез, – диде. – Рухи яктан да, физик яктан да сәламәт кешеләр булып үсәрсез!» Әтисе бу ниятләрнең барысын да чәлпәрәмә китерде. Башта бик нык аптырады, очкылык тота башлады. Авызыннан төкерек чәчеп, «ы-сс» ди-ди нидер ысылдап, ишекле-түрле йөгереп алды. Аннары буасы ерылды: «Оятсызлар! – дип кычкырды ул. – Акча түләп укытабыз, ә алар шул акчага баланы чукындыра». Шакката Амалия.

Әтисенең кыланмышы әнисен дә туйдырды, ахрысы, кулын, гадәттәгечә, күкрәгенә кушырды да торып басты, күзендәге ялкын теле керфеген көйдергәндәй булды. «Монда-а, – диде ул сузыбрак, – тавышланудан ни файда? Чебен дулап тәрәзә ватамы? Барып карадың бит шкулларына... Иле белән чукынгач, син генә нишли аласың?»

Әтисе, күкрәген уа-уа, аш бүлмәсенә чыгып китте. Анда нәрсәдер чылтырап алды...

...Ул вакытта Амалия, мәктәптән кайткач, нигә безнең почмакта икона юк, дип, ата-анасын өнсез калдырган иде. Кызга аларның миңгерәү чырае көлке тоелды, тагын да шаккатыру өчен, ул, уң кулын очындырып, маңгаена, түшенә төртенеп алды, хуплау көтеп, бер әтисенә, бер әнисенә күз ташлады. Аларның телсез калуын үзенчә юрап, мактау өмет итеп елмайды:

– Молитва укып күрсәтимме?

Әнисе шаркылдап көлә башлады. Ләкин аның күзе көлми иде.

Икенче көнне әтисе мәктәпкә китте. Кызу кеше иде ул болай. Тиз кызып китә торган гадәте бар иде. Шул гадәтенә күрә тиз генә директорга кереп, мәктәптә баласын чукындыруга үзенең катгыян кире мөнәсәбәтен белдермәкче иде. Сүзләре дә тел очында: «Бездә дин дәүләттән аерылган! Сезнең хакыгыз юк!», фәлән-төгән... һәм башка шундый кискен сүзләр. Тик директорга алай ансат кына кереп булмый икән. Ишек төбендә утыручы кызыл авызлы кыз аның юлын бүлде, директорның мәшгуль икәнен әйтеп, бераз көтәргә кушты. Беразга дигәне шактый озакка сузылды, ачуы сүрелә башлаганын тоеп, Роберт Замалиевич – аны үзе эшләгән төзелеш трестында шулай олылыйлар иде – урыныннан калкынып, ишек түрәсе кызга үзенең һәмишә монда икәнен искәртте. Тик алдындагы компьютерга кадалган кыз, авыр керфекләрен күтәрергә дә иренеп, кулын күтәреп, учын гына күрсәтте. Сезнең ишеләр монда күп килә, янәсе, ә директор берәү генә. Инде канына тарала башлаган ярсуы янә утлы төергә укмашып, Роберт Замалиевич кабинетка ыргылды. Артта кызыл авызлы кызның чинап алуы ишеккә кысылып калды. Директор – кысык күзле, табак чырайлы, мул күкрәге өстәлгә кадәр үк ташыган олы гәүдәле хатын – муенына зур көмеш тәре аскан җирән сакаллы поп белән чәй эчеп утыра иде. Бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына! Хәзер инде җайлап кына аңлатырга кирәк, интеллигент кешеләр бит, тышта егерме беренче гасыр, пнимаетели...

– Сез кем? – дип чәрелдәде директор ханым, чәрелдәде... олы гәүдәсенә карамастан, буш мичкә эчендә калган тычканныкыдай, хәтта чинабрак чыга иде тавышы. – Сез нигә рөхсәтсез бәреп керәсез? Полиция чакырам хәзер!

Роберт Замалиевич сүзне нидән башларга белмичә каушап калды. Үзенең биредә укучы Амалия Айзатуллованың әтисе булуын аңлатырга маташты. Аны монда чукынырга өйрәткәнсез, ә без – этник мөселманнар, дип бытылдады.

Ишектә ярым хәрби киемгә төренгән сакчы күренде. Директор хатын, Роберт Замалиевичның өтек-төтек сүзләренә игътибар итмәстән, шул сакчыга ябырылды:

– Син нигә мәктәпкә ят кешене керттең? Эшеңнән куам хәзер үк!

– Гафу итегез, туалетка киткән чагым иде... – Сакчы Роберт Замалиевичның җиңенә килеп ябышты.

– Позвольте...

– Не позволим! – дип чәрелдәде директор хатын. – Православие культурасын өйрәнү бездә мәҗбүри. Культураны! Аңлыйсызмы? Оныттыгызмы кайсы илдә яшәгәнне?! Әллә сез – мөселман экстремистымы? Яхшы, без тиешле урынга хәбәр итәрбез.

Роберт Замалиевич бөтенләй аңгырайды. Сакчы аны ишеккә өстери иде инде. Поп бу мәрәкәгә бөтенләй күз дә салмыйча чәй эчә иде. Директор, мул күкрәген өстәлдә биетеп, һаман кызды:

– Сез бердәм Россияне таркатырга йөрисез. Сепаратист! Мин моны болай гына калдырмыйм.

– Мин бит... мин, – дип тотлыкты Роберт Замалиевич, – киңәшергә дип кенә... – Хәер, бу сүзләрне, мәктәптән чыгып киткәч, үз-үзенә пышылдады бугай ул. Һәм, әлбәттә, чыгып киткәннән соң, ул директорның шаркылдап көлгәнен дә ишетмәде. Поп, ниһаять, кулындагы чынаягын өстәлгә куйды.

– Толерант халык татарва, – диде ул, көлемсерәп. – Алар инде безгә проблема чыгармас.

– Нинди проблема? – дип, тагын шаркылдады директор хатын. – Күрмәдеңмени, ыштаны юешләнгән иде.

Шул көннән соң мәктәптә эзе суынды Роберт Замалиевичның.

– Каникулга чыгуга ук, авылга кайтарырга кирәк Амалияне, – диде ул хатынына. – Анда әле минем әбинең әнисе дә исән, мулла булып йөри, бисмилла булса да өйрәтер кызга.

Моңарчы авылны өнәп бетермәгән хатыны да бу ниятә каршы төшмәде.

– Кайтсын шул, – диде. – Анда сөт-катык... башкасы. Барысы да натуральный.

Авыл Алатыр шәһәреннән әллә ни ерак түгел иде. Ике йөз чакрымнар булыр. Тик кендек күптән өзелгән, хатыны да шәһәрдән булгач, Роберт Замалиевич анда урык-сурык кына кайткалап китә, җәйге ялларда алар йә Анталиягә, йә якын-тирәдәге шифаханәгә баралар. Тормышлары шулай бер көйдә иде. Менә бит... авыл искә төште. Роберт Замалиевич та, институтта укытып йөргән Луиза Маратовна да, әлбәттә, моңарчы үзләренең нинди диндә булулары турында уйланганнары юк иде. Әлепне таяк дип белмәгән килеш ничек уйланасың? Ләкин күз алдында бердәнбер баланы чукындырганда, кайдадыр эчтә ниндидер кыл сискәнеп куйды. Бигрәк тә Роберт Замалиевич... Ул, мәктәптән кайтканнан соң, төне буе йоклый алмады. Таң алдыннан төш күрде: зират капкасының баганасына сөяләп, мәрхүм әтисе елап тора иде...

...Амалия, иреннәрен кысып, әнисе белән салкын гына саубуллашты. Үзе шәһәрдә калды әнә, ә кызын – сөргенгә... Әтисе инде машинасын кабызган иде. Алатырдан чыккач, иксез-чиксез кырлар җәелеп киткән, әтисе дә иркенлекне тансыклаган, ахры, тезгенне җибәрде, моңаеп торган ташландык авылларны узып, машина алга чапты.

– Синең өчен бөтенләй яңа дөнья анда, – дип, әтисе кызын юатырга маташса да, Амалия аны инде ишетми, йокыга оеган иде. Авылга килеп җиткәнен ул сизми дә калды.

Шифер түбәле тәбәнәк кенә өйдән ике карчык ашыгып чыкты. Яшьрәге Амалиянең әтисен кочаклап алды.

– Руберт, кайттыңмы, таем!

Олырак карчык Амалияне җитәкләп алды, йомшак кына аркасын какты.

– Менә бит нәберәбез дә кайткан, Алланың хикмәте.

– Киленнең быел да эше тыгыздыр инде...

Шаулашып өйгә керделәр.

– Карт әби кайда соң? – дип, әтисе як-якка карады.

– Гөлҗиан әптәйнең килене ир олан тапкан. Шуңа исем кушарга китте анай, – диде олырак карчык. – Самавыр кайнаганчы кайтып җитәр. Әле торасыздыр бит?

– Иртәгә миңа эшкә. Бүген китәргә кирәк. Амалияне генә кайтардым. Ялга чыккач, иркенләп кайтырмын әле.

– Син шулай әтәсең дә... – Яшьрәк карчык күзен сөртеп алды. Амалия аны әтисенең әнисе дип юрады.

– Кызыңны апкайтуың яхшы булган, үзең дә беләсең, җәй көне бездә җан рәхәте. Тиздән җиләкләр өлгерер. – Олы карчык елмайды. – Тик анай аны бездән тартып алыр инде.

– Барыгызга да җитәр, – дип, әнисе белән әбисен юатты Роберт, үзе берни дә аңламыйча күзен тасрайтып утырган кызының сөеп чәченнән сыйпады. Самавырны өстәлгә куйдылар, куертылган каймак, сөт-катык, бал, бавырсаклар килде. Тик әбиләр самавырны борчырга ашыкмады. Кунак мәгънәле итеп сәгатенә дә караштырып алды.

– Хәзер кайтып җитә ул. Аңардан башка ризыклану килешмәс.

– Белә-әм...

Капка шыгырдаганы ишетелде. Амалия җитез гәүдәле берәүнең ишегалдына үткәнен күреп калды. Шул мизгелдә үк ул ишектән дә килеп керде. Барысы да урыныннан торды. Амалия дә калкынды. «Директор» монда шушы әби икән дип уйлады. Кортка өйдәге ике әбидән аерылып тора, өлкән булса да – юкса болары сикереп тормаслар иде! – күзе җемелди, җиңел сөякле, йөзе дә тарттырылган барабан сыман – бер җыерчык эзе күренми.

Дәвамы бар >

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»

медицина тикшеренүе узу өчен СЕРТИФИКАТ уйната

1 **ЯЗЫЛ!**
2023 елның икенче яртыеллыгына «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына языл

2023 елның 5–15 июнь көннәрендә «Ватаным Татарстан» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 – җомга саны
444 сум 54 тиен
гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~

П2409 –
атнага дүрт тапкыр чыга
1051 сум 80 тиен
гадәти бәясе – ~~1227 сум 30 тиен~~

2 **КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ҖИБӘР!**

89179270040 info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт.

3 **БҮЛӘК ОТ!**

Сертификатлар:
1) 9 төрле УЗИ+уролог консультациясе;
2) 9 төрле УЗИ+гинеколог консультациясе;
3) остеопат ярдәме.

Тулырак сайтта: vatantat.ru

Акция 2023 елның 28 апреленнән башлап 30 июнενә кадәр дәвам итә.
Акцияне оештыручы – ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

Реклама 16+

МЦ «НУРМЕД»

«Сәламәт хатын-кыз»

*АКЦИЯ ~~5 100 сум~~ **3 100 сум**

(843) 246-76-00
(843) 209-19-29

Анализлар. Кече оча әгъзаларына УЗИ.
Сөт бизләренә УЗИ. Гинеколог консультациясе.

Адрес:
Салих Батыев ур., 1 йорт

Тулырак сайтта: nhkrt.ru

*Акция 2023 елның 30 маена кадәр дәвам итә.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШҮ СОРАЛА.

Реклама 18+



Әз-мәз мәзәк

Тормышларын яңа биттән башлаучылардан сорыйсы килә: сез иске битләрне кая куясыз ул? – гем чыгар», – дип карап тора.

* * *

– Тыныч йоклар өчен берәр мендәр тәкъдим итегез әле.
– Финанс мендәре.

* * *

Шкафта тәртип ясаганда һәр киемем миңа: «Ташлама мине, минем әле кирәгем чыгар», – дип карап тора.

* * *

– Акча биреп тор әле.
– Күпме?
– Күпме җәл түгел инде.
– Ике сумга нәрсә алмакчы буласың?

* * *

– Әйдә иртәгә киногa?
– Миндә инвентаризация.
– Алайса, тазаргач.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: Косово, алимент, аршын, аша, опера, чи, Сеул, БСТ, ас, Ирек, Байгал, Лима, Ык, инәй, Ания, па, Лиза, мат, акт, көн, шан, Наласа, аһәң, баэт, Итил.
Вертикаль: саран, сабырлык, сак, өлкә, Винарис, азан, ерганак, зат, кер, Ту, он, Лилия, Нәс, Станок, аң, белән, Вишневский, шарт, палас, Ансат, Марат, Наил.

Беләсең килсә...

1 Музыкант һәм театр эшлеклесе Ильяс Кудашев-Ашказарскийның әтисе кем булган?
а) авылда тимерче;
б) зәркән остасы;
в) тимер юл машинисты.

2 Яңа Зеландия парламенты утырган биналарның берсе формасы белән нәрсәне хәтерләтә?
а) кырмыска оясы;
б) умарта;
в) сыерлар фермасы.

3 Элеккеге заманда имән бармакка балдак кию нәрсә өмет итуне аңлаткан?
а) сугышта җиңү;
б) эштә уңышка ирешү;
в) уңышлы гаилә кору.

4 Юмор һәм ирония хисенә бай бу журналист 1 апрель көнне туган:
а) Альберт Шакиров;
б) Рәмис Латыйпов;
в) Зөлфәт Зиннуров.

Җаваплар: 1.в); 2.б); 3.б); 4.а).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Индекс П2435
Тираж – 14253 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 281

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+